многодетной семьи на дополнительную поддержку со стороны государства. Кроме того, сама по себе рассматриваемая мера социальной поддержки предоставляется только тем многодетным семьям, которые уже признаны нуждающимися в улучшении жилищных условий и состоят на соответствующем учете. Следовательно, совместная регистрация всех членов многодетной семьи, как это предусмотрено в оспариваемой норме, не может выступать и в качестве условия для подтверждения права на получение сертификата, поскольку нуждаемость такой семьи уже проверена в порядке, установленном жилищным законодательством, и подтверждена самим фактом постановки их органами местного самоуправления на соответствующий учет.

Из этого исходит и судебная практика, в соответствии с которой регистрация по месту жительства по смыслу статьи 3 Закона Российской Федерации «О праве граждан Российской Федерации на свободу передвижения, выбор места пребывания и жительства в пределах Российской Федерации» не является способом подтверждения как состава многодетной семьи, так и ее материальной обеспеченности (определение Судебной коллегии по гражданским делам Верховного Суда Российской Федерации от 18 апреля 2007 года № 81-Г07-2).

С учетом изложенного Конституционный суд Республики Татарстан приходит к выводу, что предусмотренное в обжалуемой норме регулирование, устанавливающее наличие регистрации всех членов многодетной семьи по одному месту жительства в качестве обязательного условия для получения вышеназванной меры социальной поддержки, фактически представляет собой формально-юридическое препятствие для реализации ими права на улучшение жилищных условий. Предоставление сертификатов тем многодетным семьям, члены которых имеют совместную регистрацию по одному месту жительства, при невозможности получения аналогичных социальных гарантий семьями, относящимися к той же категории, но не имеющими совместной регистрации, влечет неоправданную дифференциацию, которая, в свою очередь, приводит к снижению уровня их социальной защиты. Такое правовое регулирование в нарушение конституционного принципа равенства приводит не только к необоснованным различиям в объеме социальных прав многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, но и искажает само существо рассматриваемого права, что не согласуется с конституционно значимыми целями возможных ограничений прав и свобод человека и гражданина.

Данный подход согласуется с правовой позицией Конституционного Суда Российской Федерации, из которой следует, что любая дифференциация правового регулирования, приводящая к различиям в правах и обязанностях субъектов права, должна осуществляться законодателем с соблюдением требований Конституции Российской Федерации, в том числе вытекающих из универсального принципа равенства, в силу которого различия допустимы лишь в том случае, если они объективно оправданы,

обоснованы и преследуют конституционно значимые цели, а используемые для достижения этих целей правовые средства соразмерны им; соблюдение данного принципа означает, помимо прочего, запрет вводить такие различия в правах лиц, принадлежащих к одной и той же категории, которые не имеют объективного и разумного оправдания (постановления от 3 ноября 1998 года № 25-П, от 28 мая 2010 года № 12-П).

Европейский Суд по правам человека в своей прецедентной практике также исходит из недопустимости установления различий, необоснованно ставящих семьи, воспитывающие детей, в неравное положение в вопросах доступа к льготам, направленным на поддержку детей и семьи в целом (постановление от 31 марта 2009 года по делу «Веллер (Weller) против Венгрии»).

Таким образом, подпункт «а» пункта 4 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 "О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий"», в той мере, в какой его положения ставят право на получение сертификата многодетными семьями, нуждающимися в улучшении жилищных условий, в зависимость от наличия совместной регистрации всех членов семьи по одному месту жительства, не соответствует статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 38 (части первая и третья), 54 (часть первая), 55 Конституции Республики Татарстан.

Кабинету Министров Республики Татарстан надлежит — исходя из требований Конституции Республики Татарстан и с учетом основанных на ее положениях правовых позиций Конституционного суда Республики Татарстан — внести в действующее правовое регулирование надлежащие изменения, вытекающие из настоящего Постановления. Впредь до внесения таких изменений правоприменителям следует минимизировать излишний формализм в подходе к оценке правомочности многодетных семей на получение сертификата и исходить прежде всего из необходимости принятия всех зависящих от них законных мер, направленных на реальное улучшение жилищных условий, обеспечивающих достойный уровень жизни состоящих на учете в качестве нуждающихся в улучшении жилищных условий многодетных семей, имеющих пять и более детей, а также недопущения повторения выявленных Конституционным судом Республики Татарстан отступлений от конституционного правопорядка.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, частями первой и второй статьи 66, частями первой, второй и шестой статьи 67, статьями 68, 69, 71 и 73, пунктом 2 части первой статьи 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**постановил:**

1. Признать подпункт «а» пункта 4 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 "О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий"», в той мере, в какой его положения ставят право на получение сертификата многодетными семьями, нуждающимися в улучшении жилищных условий, в зависимость от наличия совместной регистрации всех членов семьи по одному месту жительства, не соответствующим Конституции Республики Татарстан.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан надлежит — исходя из требований Конституции Республики Татарстан и с учетом основанных на ее положениях правовых позиций Конституционного суда Республики Татарстан — внести в действующее правовое регулирование надлежащие изменения, вытекающие из настоящего Постановления.

3. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

4. Настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU). Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 83-П

Конституционный суд<br>Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**гражданин А.В. Орлов шикаятенә бәйле рәвештә «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2019 ел
30 май
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101, 103 һәм 113 статьяларына таянып,

ачык күчмә суд утырышында «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин А.В. Орлов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, яклар — гражданин А.В. Орлов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы юридик бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең хокукый экспертиза бүлеге мөдире М.В. Ляукин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары — Татарстан Республикасы Дәүләт

Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Р.С. Ибраһимов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге әйдәп баручы консультанты Р.Р. Мингалиев, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау бүлеге башлыгы урынбасары Н.В. Сапрыкина чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.В. Орлов «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 4 пунктындагы «а» пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «а» пунктчасы буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак җирле үзидарә органнарында исәптә торучы, ата-аналар белән теркәлгән һәм яшәгән, үз гаиләләрен булдырмаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр сертификат алу хокукына ия (күпбалалы гаиләнең үз гаиләләрен корган балаларына никахлары теркәлгән яки үз баласы (балалары) булган балигъ балалар керә) (алга таба — күпбалалы гаилә).

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин А.В. Орловның хатыны белән ун баласы бар һәм алар фатирда бергә наем шартнамәсе нигезендә торалар. Ләкин әлеге фатирда даими яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче генә теркәлгән, чөнки торак милекчесе аның хатынын һәм балаларын теркәүгә ризалыгын бирмәгән.

Алар хатынының ата-анасы милкендә булган башка фатирда теркәлгәннәр, әмма анда яшәмиләр.

Гражданин А.В. Орлов күрсәткәнчә, ул хатыны һәм балалары белән 2013 елдан торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә тора. Шул ук вакытта аларга торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификат алу исемлекләренә бер торак урында бергә теркәлмәү сәбәпле кертүдән баш тарталар.

Мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Үзәк районы администрациясе үзенең баш тартуын нигезләп, турыдан-туры дәгъва белдерелә торган нигезләмәгә мөрәҗәгать итә, ул сертификат бирү өчен мәҗбүри шарт итеп күпбалалы гаилә әгъзаларының бергә яшәүләренә өстәмә рәвештә аларның бер торак урында бергә теркәлүләрен билгели.

Ләкин, гражданин А.В. Орлов фикеренчә, мондый өстәмә шарт аның Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнгән социаль тәэминатка хокукын һәм тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларын боза. Дәгъва белдерелә торган норма, аның раславы буенча, бер үк категориягә кергән гражданнарны (бергә яшәүче һәм бер торак урында теркәлгән күпбалалы гаиләләр, шулай ук бергә яшәүче, әмма бер торак урында теркәлмәгән күпбалалы гаиләләр), Кагыйдәләр белән каралган сертификатны алу хокукын гамәлгә ашырганда тигез булмаган хәлгә куя.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.В. Орлов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасын сертификат алу хокукына бары тик гаилә әгъзалары бер торак урында теркәлгән күпбалалы гаилә генә ия дип билгеләгән өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм иркен үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм гражданин хокукларының һәм ирекләренең яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә тигезлеген гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында, ана һәм бала

сәламәтлеген тәэмин итү һәм балалар тәрбияләү турында кайгырта; һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасы нигезләмәләре торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең сертификат алу хокукын барлык гаилә әгъзаларының бер яшәү урыны буенча бергә теркәлүләре булу-булмауга бәйле иткән дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның

гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 24 пунктчасы нигезендә балалары булган гаиләләргә (шул исәптән күпбалалы гаиләләргә, ялгыз ата-анага) социаль ярдәм мәсьәләләрен хәл итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының уртак карамактагы мәсьәләләр буенча әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән мөстәкыйль гамәлгә ашырыла торган (федераль бюджеттан кергән субвенцияләрдән тыш) вәкаләтләренә керә. Шулай ук әлеге Федераль закон белән шул каралган: Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын федераль законнарда күрсәтелгән хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйсез рәвештә билгеләргә хокуклы. Аталган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

«Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән Россия Федерациясе составындагы республикалар хөкүмәтләренә, крайларның, өлкәләрнең, автоном берәмлекләрнең, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренең башкарма хакимият органнарына, регионның социаль-икътисади һәм демографик үсешендә милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, күпбалалы һәм өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гаиләләр категорияләрен һәм күпбалалы гаиләләр өчен социаль ярдәм чараларын билгеләү йөкләнгән булган (1 пунктның «а», «б» пунктчалары).

«Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы 216-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән ата-ана белән бергә яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган биш һәм аннан күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр торак урыннарны чираттан тыш алу хокукына ия гражданнар категориясенә керә дип билгеләнгән.

Күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренә беркетелгән торак урыннары булмаган затларны торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарны кабул иткән, аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 ма-

ендагы 326 номерлы карары белән үзгәрешләр кертелгән, шулай ук дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләр расланган.

Шулай итеп, Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләрен раслап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

3. Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), Татарстан Республикасы Конституциясе шуны беркетә: гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр); һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш). Мәгънәләре буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Россия Федерациясе Конституция Суды карарларында билгеләп үтелгәнчә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 38 һәм 39 статьялары белән беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә гаилә һәм балаларны социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә иркле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар, 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак сатып алу өчен түләүсез нигездә субсидия бирү рәвешендәге социаль ярдәм чарасы ата-аналар белән теркәлгән һәм яшәгән, үз гаиләләрен булдырмаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне

(күпбалалы гаиләнең үз гаиләләрен корган балаларына никахлары теркәлгән яки үз баласы (балалары) булган балигъ балалар керә) (Кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «а» пунктчасы) торак белән тәэмин итү буенча өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән.

Үзенең хокукый табигате буенча әлеге социаль ярдәм чарасы, Татарстан Республикасы Конституция суды элегрәк билгеләп үткәнчә, социаль тәэмин итүнең мәҗбүри төренә керми һәм, асылда, күрсәтелгән гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрүнең өстәмә алымы булып тора; Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән республика бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, мөстәкыйль билгели (2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы карар, 2011 елның 11 октябрендәге 13-О номерлы билгеләмә).

Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак җирле үзидарә органнарында исәптә торучы күпбалалы гаиләләр аларны әлеге субсидияне алу хокукын раслый торган сертификат (алга таба — сертификат) бирү хокукына ия күпбалалы гаиләләр исемлегенә кертү максатларында туры килергә тиеш булган берничә шарт куйган.

Дәгъва белдерелә торган норманың турыдан-туры эчтәлеген анализлаудан күренгәнчә, карала торган эш мөнәсәбәтендә күпбалалы гаиләнең сертификат алуга хокуклы булуын билгеләгәндә төп таләпләр булып балалар һәм ата-аналарның бергә яшәүләре, шулай ук аларның яшәү урыны буенча бер торак урында теркәлүләре тора.

Торак шартларын яхшыртуга дәгъва итүче гаилә әгъзаларының бергә яшәве турындагы таләп «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Президенты Указындагы шундый ук таләпне кабатлый һәм үзенең хокукый мәгънәсе буенча турыдан-туры Россия Федерациясе Торак кодексының гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак тану, шулай ук гражданның һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләү тәртибен регламентлаштыра торган 31 һәм 51 статьяларыннан килеп чыга, алар күпбалалы гаиләне тиешле исәпкә куйганда кулланылырга тиеш.

Күпбалалы гаилә әгъзаларының барысының да бер яшәү урыны буенча теркәлүләре турындагы таләпкә килгәндә, ул Татарстан Республикасы Президентының аталган Указында да, Россия Федерациясе Торак кодексының китерелгән нигезләмәләрендә дә юк. Шул ук вакытта күпбалалы гаиләне торак белән тәэмин итү өчен сертификат бирүнең мәҗбүри шартларыннан берсе буларак аның конституциячеллеген бәяләү Россия Федерациясе Граждан кодексының 20 статьясындагы 1 пункты һәм «Россия

Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» 1993 елның 25 июнендәге 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 2 һәм 3 статьялары белән беркетелгән «яшәү урыны» төшенчәсенә мөрәҗәгать итмичә мөмкин түгел, аларда гражданның яшәү урыны буларак ул Россия Федерациясе законнары белән каралган нигезләрдә даими яки күпчелек рәвештә яши торган һәм яшәү урыны буенча теркәлгән торак урын билгеләнгән. Әлеге Россия Федерациясе Законының 2 статьясындагы 4 абзацы нигезендә Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны буенча теркәлүе Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны турында һәм аның әлеге яшәү урынында булуы хакында мәгълүматны теркәү исәбе органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәү булып тора. Шул ук вакытта күрсәтелгән Россия Федерациясе Законының 3 статьясындагы икенче өлеше буенча теркәлү яисә аның булмавы гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары конституцияләрендә (уставларында) һәм законнарында каралган хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруны чикләргә нигез яисә аның шарты булып тора алмый.

Китерелгән закон нигезләмәләре шуны раслый: теркәү исәбенә алу институты хәбәр итү характерына ия, теркәлү гражданның яшәү урыны буенча булу фактын чагылдыра торган хәлләрнең берсе генә булып тора.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килә, ул берничә тапкыр күрсәткәнчә, теркәлү факты яки аның булмавы үзеннән-үзе граждан өчен нинди дә булса хокуклар һәм бурычлар тудырмый һәм «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 3 статьясындагы икенче өлеше буенча гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектларының закон актларында каралган хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруны чикләргә нигез яисә аның шарты булып тора алмый; гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килми торган мәгънәдә тору урыны яки яшәү урыны буенча теркәлүе хәбәр итү характерына ия булган һәм гражданның тору яки яшәү урыны буенча булу фактын чагылдыра торган аларны Россия Федерациясе территориясе чикләрендә исәпкә алуның федераль закон белән каралган ысулы булып тора; теркәү исәбе органнары гражданның тору һәм яшәү урынын сайлаганда ирекле ихтыяр белдерү актын расларга гына хокуклы, шуңа күрә теркәү исәбе рөхсәт характерында була алмый (1995 елның 24 ноябрендәге 14-П номерлы, 1996 елның 4 апрелендәге 9-П номерлы, 1998 елның 15 гыйнварындагы 2-П номерлы, 1998 елның 2 февралендәге 4-П номерлы, 2011 елның 2 июнендәге 11-П номерлы карарлар, 2000 елның 13 июлендәге 185-О номерлы, 2008 елның 6 октябрендәге 619-О-П номерлы, 2009 елның 13 октябрендәге 1309-О-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Моннан чыгып, күпбалалы гаиләнең барлык әгъзаларының бер яшәү урыны буенча теркәлүләре булмау аларның яшәү урынын мәҗбүри рәвештә теркәү исәбе органнарыннан гына килә торган түгел, ә башка мәгълүматлар нигезендә билгеләү мөмкинлеген кире какмый һәм, һәрхәлдә, күпбалалы гаиләнең дәүләт тарафыннан өстәмә ярдәм алуга хокукын шик астына куя алмый. Моннан тыш, карала торган социаль ярдәм чарасы үзеннән-үзе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип табылган һәм тиешле исәптә торучы күпбалалы гаиләләргә генә бирелә. Димәк, дәгъва белдерелә торган нормада каралганча, күпбалалы гаиләнең барлык әгъзаларының бергә теркәлүе сертификат алу хокукын раслау шарты була алмый, чөнки мондый гаиләнең мохтаҗлыгы торак законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерелгән һәм аларның җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле исәпкә куелу факты белән расланган.

Моңа суд практикасы да таяна, аның нигезендә «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 3 статьясы мәгънәсе буенча яшәү урыны буенча теркәлү күпбалалы гаилә составын да, аның матди тәэмин ителешен дә раслау ысулы булып тормый (Россия Федерациясе Югары Судының Граждан эшләре буенча суд коллегиясенең 2007 елның 18 апрелендәге 81-Г07-2 номерлы билгеләмәсе).

Бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъва белдерелә торган нормада каралган югарыда аталган социаль ярдәм чарасын алу өчен мәҗбүри шарт буларак күпбалалы гаиләнең барлык әгъзаларының бер яшәү урыны буенча теркәлүләре булуны билгели торган җайга салу фактта аларның торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыру өчен формаль-юридик киртә булып тора дигән нәтиҗәгә килә. Гаилә әгъзалары бер яшәү урыны буенча теркәлгән күпбалалы гаиләләргә сертификатларны шул ук категориягә караган, әмма бергә теркәлмәгән гаиләләрнең тиңдәш социаль гарантияләр алу мөмкинлеге булмаганда бирү акланмаган дифференциациягә китерә, ул, үз чиратында, аларның социаль яклау дәрәҗәсен киметүгә китерә. Мондый хокукый җайга салу, тигезлек конституциячел принцибын бозып, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең социаль хокуклары күләмендә нигезсез аермалар булуга гына китереп калмыйча, карала торган хокукның асылын да боза, бу исә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен мөмкин булган чикләүнең конституциячел әһәмиятле максатлары белән ярашмый.

Әлеге алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килә, аның нигезендә хокук субъектларының хокуклары һәм бурычлары аермасына китерә торган хокукый җайга салуны теләсә ничек дифференциацияләү закон чыгаручы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе таләпләрен, шул исәптән универсаль тигезлек принцибына бәйле таләпләрне үтәп гамәлгә ашырылырга тиеш, аның нигезендә аер-

малар бары тик объектив акланган, нигезләнгән һәм конституциячел әһәмиятле максатларга туры килә торган очракта гына рөхсәт ителә, ә әлеге максатларга ирешү өчен файдаланыла торган хокукый чаралар шуларга тиң; әлеге принципны үтәү, башкалар белән беррәттән, объектив һәм нигезле аклануга ия булмаган бер үк категориягә караган затларның хокукларына мондый аермалар кертүне тыю дигәнне аңлата (1998 елның 3 ноябрендәге 25-П номерлы, 2010 елның 28 маендагы 12-П номерлы карарлар).

Кеше хокуклары буенча Европа Суды үзенең прецедент практикасында шулай ук бала тәрбияләүче гаиләләрне гомумән балаларга һәм гаиләгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән ташламалардан файдалану мәсьәләләрендә нигезсез рәвештә тигезсез халәткә куя торган аермалар билгеләүгә юл куелмау тиешлегеннән чыгып эш итә («Веллер (Weller) Венгриягә каршы» эше буенча 2009 елның 31 мартындагы карар).

Шулай итеп, «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасы нигезләмәләре торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең сертификат алу хокукын барлык гаилә әгъзаларының бер яшәү урыны буенча бергә теркәлүләре булу-булмауга бәйле иткән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының аның нигезләмәләренә таянган хокукый позицияләрен исәпкә алып — гамәлдәге хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертергә тиеш. Мондый үзгәрешләр кертелгәнче, хокук кулланучылар күпбалалы гаиләләрнең сертификат алуга хокуклылыгын бәяләүгә якын килүдә артык формальлекне минимальләштерергә һәм беренче чиратта торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торучы биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрнең лаеклы тормыш дәрәҗәсен тәэмин итә торган торак шартларын чыннан да яхшыртуга юнәлдерелгән аларга бәйле барлык законлы чараларны күрү, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан ачыкланган конституциячел хокук тәртибеннән тайпылуларның кабатлануына юл куймау кирәклегеннән чыгып эш итәргә тиешләр.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының

6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 4 пунктындагы «а» пунктчасын нигезләмәләре торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең сертификат алу хокукын барлык гаилә әгъзаларының бер яшәү урыны буенча бергә теркәлүләре булу-булмауга бәйле иткән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының аның нигезләмәләренә таянган хокукый позицияләрен исәпкә алып — гамәлдәге хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертергә тиеш.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 83-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.А. Шмакова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

24 января
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина А.А. Шмакова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин А.А. Шмаков с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан). В соответствии с оспариваемым положением инвалидам, страдающим тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в перечне, предусмотренном пунктом 4 части 1 статьи 51 Жилищного кодекса Российской Федерации, а также семьям, имеющим детей-инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в данном перечне, признанным в установленном порядке нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, вставшим на учет после 1 января 2005 года, предоставляется жилищная субсидия (единовременная денежная выплата) на приобретение жилого помещения.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявитель является инвалидом второй группы по заболеванию, входящему в Перечень тяжелых форм хронических заболеваний, при которых невозможно совместное проживание граждан в одной квартире, утвержденный приказом Министерства здравоохранения Российской Федерации от 29 ноября 2012 года № 987н (далее также — Перечень), и в 2018 году поставлен на учет в качестве нуждающегося в улучшении жилищных условий по договору социального найма во внеочередном порядке.

Как считает гражданин А.А. Шмаков, согласно пункту 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан он имеет право на получение жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения.

Заявитель указывает, что в соответствии с пунктом 2 Порядка предоставления жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения за счет средств бюджета Республики Татарстан, утвержденного постановлением

Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2016 года № 236 «О предоставлении жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения за счет средств бюджета Республики Татарстан отдельным категориям инвалидов», Исполнительный комитет муниципального образования города Казани в течение пяти рабочих дней со дня постановки его на учет должен был направить информацию о нем в Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан для формирования сводного списка получателей субсидии. В свою очередь информация о постановке его на учет в качестве нуждающегося в улучшении жилищных условий по договору социального найма в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани должна была поступить из администрации Советского района муниципального образования города Казани. Однако гражданин А.А. Шмаков отмечает, что до настоящего времени его документы в установленном порядке в уполномоченный орган не направлены, в связи с чем он обратился в суд, решением которого в удовлетворении его исковых требований было отказано.

Заявитель также неоднократно обращался в органы государственной власти Республики Татарстан и в органы местного самоуправления по данному вопросу, из ответов которых следует, что для включения его в сводный список получателей жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) он дополнительно должен быть признан нуждающимся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования.

Гражданин А.А. Шмаков указывает, что оспариваемая статья 8.2 Закона Республики Татарстан была введена в 2014 году и в первоначальной редакции предусматривала предоставление жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) определенным категориям инвалидов, признанных нуждающимися в жилых помещениях, вставших на учет после 1 января 2005 года. Однако 5 декабря 2015 года в обжалуемом пункте 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан слова «нуждающимися в жилых помещениях» были заменены словами «в установленном порядке нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования».

Заявитель подчеркивает, что статья 8.2 Закона Республики Татарстан была введена в целях исполнения пункта 4 части 1 статьи 51 Жилищного кодекса Российской Федерации, хотя сама статья 51 данного Кодекса не содержит дополнительного требования о том, чтобы граждане, относящиеся к вышеуказанной категории инвалидов, в целях признания их нуждающимися в жилых помещениях, предоставляемых по договорам социального найма, дополнительно еще должны были быть признаны в установленном порядке нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования. При этом он также отмечает, что

основания и порядок предоставления жилых помещений по договорам социального найма регулируются главой 7 Жилищного кодекса Российской Федерации, а основания и порядок предоставления жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования — главами 8.1 и 8.2 данного Кодекса. То есть он усматривает противоречие между федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан и подчеркивает, что на основании части 2 статьи 4 Конституции Российской Федерации федеральные законы имеют верховенство на всей территории Российской Федерации. В соответствии с частью 8 статьи 5 Жилищного кодекса Российской Федерации в случае несоответствия норм жилищного законодательства, содержащихся в федеральных законах и иных нормативных правовых актах Российской Федерации, законах и иных нормативных правовых актах субъектов Российской Федерации, нормативных правовых актах органов местного самоуправления, положениям данного Кодекса применяются положения Жилищного кодекса Российской Федерации.

Следовательно, по мнению заявителя, требование законодательства Республики Татарстан, предписывающее вышеуказанной категории инвалидов дополнительное признание в установленном порядке нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования помимо того, что они уже признаны нуждающимися в жилых помещениях, предоставляемых по договорам социального найма, и включены в список лиц, имеющих внеочередное право на обеспечение жилой площадью, является незаконным и не подлежащим применению.

На основании изложенного гражданин А.А. Шмаков просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» в части необходимости дополнительного признания инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в Перечне, нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования не соответствующим статьям 1 (часть первая), 2, 4 (часть первая), 13, 27 (часть первая), 29 (части первая и вторая), 54 (часть первая), 55 и 58 Конституции Республики Татарстан.

2. Конституционный суд Республики Татарстан, изучив представленные гражданином А.А. Шмаковым материалы, не находит оснований для принятия его жалобы к рассмотрению.

Оспариваемый заявителем пункт 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан уже неоднократно был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан. В своих определениях Конституционный суд Республики Татарстан отмечал, что предусмотренное обжалуемым Законом Республики Татарстан правовое регулирование является дополнительной гарантией обеспечения конституционного права граждан на жилище

посредством предоставления им целевой субсидии, направлено на установление способа реализации отдельными категориями граждан их права на улучшение жилищных условий, а также на определение данных категорий граждан, в число которых наряду с другими включены инвалиды и семьи, имеющие детей-инвалидов. При этом, как указывал Конституционный суд Республики Татарстан, установленное оспариваемым Законом Республики Татарстан правовое регулирование представляет собой дополнительную меру социальной поддержки отдельных категорий граждан, установление которой является правом, а не обязанностью Республики Татарстан. Это означает, что основания и условия ее предоставления определяются республикой самостоятельно с учетом имеющихся на данном этапе социально-экономического развития финансовых и иных материальных возможностей (определения от 8 июля 2016 года № 12-О, от 12 июля 2017 года № 32-О, от 10 сентября 2018 года № 19-О и от 28 сентября 2018 года № 29-О).

Такой подход согласуется и с правовой позицией Конституционного Суда Российской Федерации, который отмечал, что, относя социальную защиту, включая социальное обеспечение, к совместному ведению Российской Федерации и ее субъектов (статья 72, пункт «ж» части 1), Конституция Российской Федерации не устанавливает конкретные способы и объемы такой защиты, предоставляемой тем или иным категориям граждан. Решение этих вопросов является прерогативой законодателя, который при определении гарантий реализации прав, закрепленных в Конституции Российской Федерации, располагает достаточно широкой свободой усмотрения в выборе мер социальной защиты, критериев их дифференциации, регламентации условий и порядка предоставления; он вправе также избирать и изменять формы (способы) их предоставления (Постановление от 10 ноября 2009 года № 17-П; Определение от 9 ноября 2010 года № 1439-О-О).

Условием предоставления жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения в соответствии с оспариваемой нормой является признание в установленном порядке инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в Перечне, нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования. Порядок учета граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, утвержден постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 7 июня 2018 года № 432. Согласно пункту 2.1 данного Порядка принятие на учет указанных граждан осуществляется на основании представленных ими заявлений и необходимых документов. В силу пункта 2 Порядка предоставления жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения за счет средств бюджета Республики Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18

апреля 2016 года № 236, предоставление субсидий на приобретение жилья таким гражданам производится в порядке очередности согласно сводному списку граждан — получателей субсидии, сформированному Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан на основании списков исполнительных комитетов муниципальных образований Республики Татарстан, в которых получатели субсидий были признаны в установленном порядке нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования.

Из вышеуказанного следует, что реализация предусмотренного оспариваемой нормой права инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в Перечне, на получение жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения, вопреки доводам гражданина А.А. Шмакова, носит заявительный характер и требует от граждан, претендующих на ее получение, совершения определенных действий.

Таким образом, обжалуемое положение пункта 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан принято в рамках предоставленных Республике Татарстан полномочий, само по себе не содержит ограничений в реализации права граждан, в том числе заявителя, на получение жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения, не может рассматриваться как нарушающее конституционные права граждан и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой.

Разрешение же вопроса о законности и обоснованности судебных постановлений и решений должностных лиц правоприменительных органов по конкретному делу гражданина А.А. Шмакова, а также иных вопросов, поставленных заявителем, не входит в полномочия Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73, 100 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.А. Шмакова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря

2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» в части необходимости дополнительного признания инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в Перечне, нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования для получения жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения, поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение иных поставленных заявителем вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину А.А. Шмакову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 2-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Шмаков шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
24 гыйнвар
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин А.А. Шмаков шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.А. Шмаков «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 8.2 статьясындагы 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъвалана торган нигезләмә буенча билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә (алга таба шулай ук — Исемлек) кергән авыру буенча икенче төркем инвалиды һәм ул торак шартларын чираттан тыш тәртиптә социаль наем шартнамәсе буенча яхшыртуга мохтаҗ буларак 2018 елда исәпкә куелган.

Гражданин А.А. Шмаков фикеренчә, Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пункты буенча ул торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алуга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Инвалидларның аерым ка-

тегорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аны исәпкә куйган көннән алып биш эш көне эчендә аның турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына субсидия алучыларның җыелма исемлеген төзү өчен җибәрергә тиеш булган. Үз чиратында аның торак шартларын социаль наем шартнамәсе буенча яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелуы турында мәгълүмат Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Совет районы администрациясеннән килергә тиеш булган. Ләкин гражданин А.А. Шмаков билгеләгәнчә, хәзерге вакытка кадәр аның документлары билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органга җибәрелмәгән, шуңа бәйле рәвештә ул судка мөрәҗәгать иткән, аның карары белән дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук әлеге мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән, аларның җавапларыннан күренгәнчә, аны торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алучыларның җыелма исемлегенә кертү өчен ул өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылырга тиеш.

Гражданин А.А. Шмаков күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган 8.2 статьясы 2014 елда кертелгән һәм беренче редакциясендә торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) торак урыннарга мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан инвалидларның аерым категорияләренә бирүне күздә тоткан. Әмма 2015 елның 5 декабрендә Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы дәгъвалана торган 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ» сүзләренә үзгәртелгән.

Мөрәҗәгать итүче ассызыклаганча, Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясы Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктын үтәү максатларында кертелгән, шулай да әлеге Кодексның 51 статьясында инвалидларның югарыда күрсәтелгән категориясенә керә торган гражданнар, аларны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ дип тану максатларында, өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урынна-

рына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган булырга тиеш дигән өстәмә таләп юк. Шул ук вакытта ул социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нигезләре һәм тәртибе Россия Федерациясе Торак кодексының 7 бүлеге, ә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нигезләре һәм тәртибе әлеге Кодексның 8.1 һәм 8.2 бүлекләре тарафыннан җайга салына дип билгеләп үтә. Ягъни ул федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары арасында каршылыклар күрә һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 4 статьясындагы 2 өлеше нигезендә федераль законнарның Россия Федерациясенең бөтен территориясендә өстен булуын ассызыклый. Россия Федерациясе Торак кодексының 5 статьясындагы 8 өлеше нигезендә федераль законнардагы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларындагы, Россия Федерациясе субъектлары законнарындагы һәм башка норматив хокукый актларындагы, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларындагы торак законнары нормалары әлеге Кодекс нигезләмәләренә туры килмәгән очракта Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләре кулланыла.

Димәк, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, инвалидларның югарыда күрсәтелгән категориясенә, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ дип танылганнан соң һәм торак мәйданы белән тәэмин ителүгә чираттан тыш хокуклары булган затлар исемлегенә кертелгәннән соң да, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип өстәмә рәвештә танылу күрсәтмәсен бирә торган Татарстан Республикасы законнары таләбе законсыз һәм кулланылырга тиеш түгел.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.А. Шмаков Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктын Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылырга тиеш булуы өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 1 (беренче өлеш), 2, 4 (беренче өлеш), 13, 27 (беренче өлеш), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды гражданин А.А. Шмаков тапшырган материалларны өйрәнеп, аның шикаятен карауга алу өчен нигезләр тапмый.

Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган 1 пункты Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын берничә тапкыр тәшкил иткән иде инде. Татарстан Респуб-

ликасы Конституция суды үзенең билгеләмәләрендә билгеләп үткәнчә, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән каралган хокукый җайга салу гражданнарның торакка конституциячел хокукын аларга максатчан субсидия бирү юлы белән тәэмин итүнең өстәмә гарантиясе булып тора, гражданнарның аерым категорияләре тарафыннан аларның торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыру ысулын билгеләүгә, шулай ук алар исәбенә башкалар белән беррәттән инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр кертелгән гражданнарның әлеге категорияләрен билгеләүгә юнәлгән. Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Конституция суды күрсәткәнчә, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән хокукый җайга салу гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасы булып тора, аны билгеләү — Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы. Бу аны бирү нигезләре һәм шартлары, социаль-икътисади үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата (2016 елның 8 июлендәге 12-О номерлы, 2017 елның 12 июлендәге 32-О номерлы, 2018 елның 10 сентябрендәге 19-О номерлы һәм 2018 елның 28 сентябрендәге 29-О номерлы билгеләмәләр).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә дә туры килеп тора, ул билгеләп үткәнчә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә иректә эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Дәгъва белдерелә торган норма нигезендә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирү шарты булып Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларны билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип тану тора. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 номерлы карары белән расланган. Әлеге Тәртипнең 2.1 пункты буенча күрсәтелгән гражданнарны исәпкә алу алар тапшырган гаризалар һәм кирәкле документлар нигезендә башкарыла. Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә шундый гражданнарга торак сатып алу өчен субсидияләр бирү субсидия алучылар билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының исемлекләре нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан төзелгән субсидия алучы гражданнарның җыелма исемлеге буенча чират тәртибендә башкарыла.

Югарыда күрсәтелгәннәрдән аңлашылганча, Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алуга дәгъвалана торган норма белән каралган хокукын гамәлгә ашыру, гражданин А.А. Шмаков дәлилләренә карамастан, мөрәҗәгать итү характерына ия һәм аны алырга теләгән гражданнардан билгеле бер гамәлләр кылуны таләп итә.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктының дәгъва белдерелә торган нигезләмәсе Татарстан Республикасына бирелгән вәкаләтләр кысаларында кабул ителгән, анда үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алуга хокукын гамәлгә ашыруда чикләүләр юк, гражданнарның конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Гражданин А.А. Шмаковның конкрет эше буенча суд карарларының һәм хокук куллану органнары вазыйфаи затлары карарларының законлы һәм нигезле булу-булмавы турындагы мәсьәләне, шулай ук мөрәҗәгать итүче куйган башка мәсьәләләрне хәл итү исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясын-

дагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пункты белән Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алу өчен өстәмә рәвештә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылырга тиеш булуы өлешендә үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Шмаков шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган башка мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин А.А. Шмаковка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 2-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению ходатайства Исполнительного комитета муниципального образования города Казани об официальном разъяснении постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П по делу о проверке конституционности отдельных положений подпунктов 2.2 и 2.3 пункта 2 Правил и порядка постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в Республике Татарстан, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 15 апреля 2005 года № 190-О**

4 февраля
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение обращения Исполнительного комитета муниципального образования города Казани,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился Исполнительный комитет муниципального образования города Казани с ходатайством о разъяснении постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П по делу о проверке конституционности отдельных положений подпунктов 2.2 и 2.3 пункта 2 Правил и порядка постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в Республике Татарстан, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 15 апреля 2005 года № 190 (далее также — Правила), в связи с жалобой гражданки Ю.В. Бадановой.

Постановлением Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П отдельные положения подпунктов 2.2 и 2.3 пункта 2 Правил и порядка постановки на учет нуждающихся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки в Республике Татарстан, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 15 апреля 2005 года № 190, признаны не противоречащими Конституции Республики Татарстан, поскольку по своему конституционно-правовому смыслу в системе действующего правового регулирования они предполагают, что при расчете совокупного уровня обеспеченности общей площадью жилых помещений, приходящейся на каждого члена семьи, претендующей на улучшение жилищных условий в системе социальной ипотеки, должны учитываться все жилые помещения (доли в них), которые находятся у них в собственности и (или) пользовании по договору найма, а также жилое помещение, право постоянного проживания в котором им предоставил собственник такого помещения путем вселения (регистрации) их как членов

своей семьи; при этом суммарный размер общей площади данных жилых помещений должен рассчитываться пропорционально количеству всех пользующихся этими жилыми помещениями членов семьи, включая собственника жилого помещения, независимо от факта их совместного проживания (регистрации).

Согласно пункту 2 резолютивной части постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П правоприменительные решения, принятые по делу заявительницы и основанные на положениях подпунктов 2.2 и 2.3 пункта 2 Правил в истолковании, расходящемся с их конституционно-правовым смыслом, выявленным Конституционным судом Республики Татарстан в данном постановлении, подлежат пересмотру в установленном порядке, если для этого нет иных препятствий.

Решением Советского районного суда города Казани административное исковое заявление к муниципальному казенному учреждению «Администрация Советского района Исполнительного комитета муниципального образования города Казани» о признании незаконным распоряжения главы администрации Советского района Исполнительного комитета муниципального образования города Казани и осуществлении постановки на учет в системе социальной ипотеки было удовлетворено. Однако апелляционным определением Верховного суда Республики Татарстан решение Советского районного суда города Казани отменено в части возложения обязанности на муниципальное казенное учреждение «Администрация Советского района Исполнительного комитета муниципального образования города Казани» принять Ю.В. Баданову на учет в качестве нуждающейся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки с момента обращения; в этой части принято новое решение, которым на муниципальное казенное учреждение «Администрация Советского района Исполнительного комитета муниципального образования города Казани» возложена обязанность повторно рассмотреть заявление Ю.В. Бадановой о постановке на учет в качестве нуждающейся в улучшении жилищных условий в системе социальной ипотеки с момента обращения. В остальной части решение суда оставлено без изменения, апелляционная жалоба муниципального казенного учреждения «Администрация Советского района Исполнительного комитета муниципального образования города Казани» — без удовлетворения.

Как указывает Исполнительный комитет муниципального образования города Казани в своем ходатайстве, постановлением Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П определено, что, в случае если семья, претендующая на получение жилого помещения по программе социальной ипотеки, зарегистрирована по месту жительства в жилом помещении, находящемся в собственности иного лица (собственника), расчет обеспеченности должен производиться с учетом собственника жилого помещения, не претендующего на получение жилого помещения по программе социальной ипотеки. В ходатайстве отмечается, что при этом у собственника жилого помещения, в котором про-

живает семья, претендующая на улучшение жилищных условий, могут иметься иные жилые помещения в собственности или на условиях найма.

Таким образом, по мнению заявителя, в постановлении Конституционного суда Республики Татарстан не определено, необходимо ли учитывать иные жилые помещения, находящиеся в собственности и (или) пользовании у собственника, не претендующего на жилое помещение по программе социальной ипотеки.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Исполнительный комитет муниципального образования города Казани просит разъяснить выводы, содержащиеся в постановлении Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П, а именно, подлежат ли учету иные жилые помещения, находящиеся в собственности или на условиях найма у собственников, не претендующих на получение жилья по программе социальной ипотеки, но предоставивших свое жилое помещение члену семьи, желающему получить жилые помещения по программе социальной ипотеки.

2. В соответствии со статьей 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» официальное разъяснение решения Конституционного суда Республики Татарстан дается только самим Конституционным судом Республики Татарстан в своем заседании по ходатайству органов и лиц, имеющих право на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан, других органов и лиц, которым оно направлено. Как уже отмечал Конституционный суд Республики Татарстан, по смыслу данной нормы в ее взаимосвязи со статьей 68 указанного Закона Республики Татарстан официальное разъяснение не может быть простым воспроизведением решения суда и не должно выходить за пределы произведенной Конституционным судом Республики Татарстан проверки конституционности соответствующего нормативного правового акта (определения от 4 октября 2001 года № 5-О, от 14 декабря 2005 года № 11-О и др.).

Конституционный Суд Российской Федерации также указывал, что ходатайство о даче официального разъяснения не может быть рассмотрено, если поставленные в нем вопросы не требуют какого-либо дополнительного истолкования решения по существу или формулирования новых правовых позиций (определения от 20 апреля 2010 года № 593-О-Р, от 24 сентября 2013 года № 1270-О-Р, от 24 декабря 2013 года № 1928-О-Р и др.).

В постановлении от 28 февраля 2018 года № 78-П Конституционный суд Республики Татарстан указал, что, если гражданин и члены его семьи, претендующие на участие в программе социальной ипотеки, проживают (зарегистрированы) в жилом помещении, принадлежащем на праве собственности лицу, которое является по смыслу подпункта 2.5 пункта 2 Правил членом их семьи и проживает (зарегистрирован) в этом же жилом помещении, расчет общей площади жилых помещений, приходящейся на одного члена данной семьи, включая собственника, осуществляется пропорцио-

нально количеству проживающих совместно членов семьи исходя из суммарной площади всех жилых помещений, принадлежащих им на праве пользования и (или) собственности.

Ссылаясь на необходимость учета суммарной площади всех жилых помещений, Конституционный суд Республики Татарстан исходил из того, что при оценке нуждаемости семьи, претендующей на улучшение жилищных условий в системе социальной ипотеки, следует учитывать все жилые помещения, имеющиеся как в собственности, так и в распоряжении (пользовании) такой семьи. Иными словами, применительно к поставленному в рассматриваемом ходатайстве вопросу, это означает, что, в случае если семья, претендующая на получение жилого помещения по программе социальной ипотеки, зарегистрирована по месту жительства в жилом помещении, находящемся в собственности иного лица (собственника), в качестве членов его семьи, расчет совокупного уровня обеспеченности жилой площадью семьи, претендующей на получение жилого помещения по программе социальной ипотеки, должен производиться только с учетом тех жилых помещений, правом пользования которыми они обладают наравне с собственником. Иные жилые помещения такого собственника, правом пользования которыми члены его семьи, претендующие на получение жилого помещения по программе социальной ипотеки, не обладают, при осуществлении такого расчета не учитываются.

Тем самым Конституционный суд Республики Татарстан пришел к выводу, что оспариваемые положения подпунктов 2.2 и 2.3 пункта 2 Правил предполагают, что при расчете совокупного уровня обеспеченности общей площадью жилых помещений, приходящейся на каждого члена семьи, претендующей на улучшение жилищных условий в системе социальной ипотеки, должны учитываться все жилые помещения (доли в них), которые находятся у них в собственности и (или) пользовании по договору найма, а также жилое помещение, право постоянного проживания в котором им предоставил собственник такого помещения путем вселения (регистрации) их как членов своей семьи. При этом суммарный размер общей площади данных жилых помещений должен рассчитываться пропорционально количеству всех пользующихся этими жилыми помещениями членов семьи, включая собственника жилого помещения, независимо от факта их совместного проживания (регистрации).

Содержание и смысл постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П выражены исчерпывающим образом, полностью основаны на нормах действующего законодательства Российской Федерации и Конституции Республики Татарстан, и какая-либо правовая неопределенность по ним отсутствует. Вследствие этого указанное постановление Конституционного суда Республики Татарстан не требует дополнительной детализации или уточнения.

Исходя из изложенного, руководствуясь статьей 6, пунктом 3 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, частями первой, второй и шестой статьи 68, ста-

тьями 69, 72, 73 и 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению ходатайства Исполнительного комитета муниципального образования города Казани об официальном разъяснении постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 28 февраля 2018 года № 78-П, поскольку для разрешения поставленного в нем вопроса официальное разъяснение данного постановления не требуется.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данному обращению окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Ю.В. Бадановой, в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани и Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 4-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибенең 2 пунктындагы 2.2 һәм 2.3 пунктчаларының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карарын рәсми аңлату турында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үтенечнамәсен карауга алудан баш тарту хакында**

2019 ел
4 февраль
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты мөрәҗәгатен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Ю.В. Баданова шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибенең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 2 пунктындагы 2.2 һәм 2.3 пунктчаларының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карарын аңлату турында үтенечнамә белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибенең 2 пунктындагы 2.2 һәм 2.3 пунктчаларының аерым нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми дип танылды, чөнки үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гамәлдәге хокукый җайга салу системасында алар социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәгъва итүче гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган торак урыннарның гомуми мәйданы белән җыелма тәэмин ителеш дәрәҗәсен хисаплаганда аларның милкендә һәм (яки)

наем шартнамәсе буенча файдалануында булган бөтен торак урыннар (алардагы өлешләр), шулай ук торак урын милекчесе аларга шул торакта даими яшәү хокукын аларны анда үз гаиләсе әгъзалары буларак кертү (теркәү) юлы белән бирелгән торак урын исәпкә алынырга тиеш дип күздә тоталар; монда әлеге торак урыннарның гомуми мәйданының җыелма күләме шул торак урыннардан файдаланучы бөтен гаилә әгъзалары санына, торак урын милекчесен кертеп, пропорциональ рәвештә, аларның бергә яшәү (теркәлү) факты булу-булмауга карамастан, хисапланырга тиеш.

Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карарының резолютив өлешендәге 2 пункты буенча мөрәҗәгать итүче эше буенча кабул ителгән һәм Кагыйдәләрнең 2 пунктындагы 2.2 һәм 2.3 пунктчалары нигезләмәләренә аларның Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсе белән туры килми торган аңлатуда таянган хокук куллану карарлары билгеләнгән тәртиптә, моның өчен башка каршылыклар булмаса, яңадан каралырга тиеш.

Казан шәһәре Совет район суды карары белән «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгының күрсәтмәсен законсыз дип тану һәм социаль ипотека системасында исәпкә куюны гамәлгә ашыру турындагы административ дәгъва гаризасы канәгатьләндерелгән. Әмма Татарстан Республикасы Югары судының апелляция билгеләмәсе белән Казан шәһәре Совет район суды карары «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесенә Ю.В. Бадановны мөрәҗәгать иткән вакыттан социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә алу бурычын йөкләү өлешендә гамәлдән чыгарылган; бу өлештә яңа карар кабул ителгән, аның белән «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесенә Ю.В. Бадановның мөрәҗәгать иткән вакыттан социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую турындагы гаризасын яңадан карау бурычы йөкләнгән. Калган өлешендә суд карары үзгәрешсез калдырылган, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең апелляция шикаяте канәгатьләндерелмәгән.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенең үтенечнамәсендә күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карары белән шул билгеләнгән: социаль ипотека программасы буенча торак урын алуга дәгъва итүче гаилә башка зат (милекче) милкендә булган торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән очракта тәэмин ителешне исәпләү социаль ипотека программасы

буенча торак урын алуга дәгъва итми торган торак урын милекчесен исәпкә алып башкарылырга тиеш. Үтенечнамәдә билгеләп үтелгәнчә, шул ук вакытта торак шартларын яхшыртуга дәгъва итүче гаилә яши торган торак урын милекчесенең милкендә яки наем шартларында башка торак урыннары булырга мөмкин.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Татарстан Республикасы Конституция суды карарында социаль ипотека программасы буенча торак урынга дәгъва итми торган милекченең милкендә һәм (яки) файдалануында булган башка торак урыннарны исәпкә алырга кирәк булу-булмавы билгеләнмәгән.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясына таянып, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карарында булган нәтиҗәләрне, атап әйткәндә, социаль ипотека программасы буенча торак алуга дәгъва итмәүче, әмма торак урынын социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алырга теләгән гаилә әгъзасына биргән милекчеләрнең милкендә яки наем шартларында булган башка торак урыннары исәпкә алынырга тиешме-юкмы икәнен аңлатуны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карарына рәсми аңлатма Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы булган органнарның һәм затларның, карар җибәрелгән башка органнарның һәм затларның үтенечнамәсе буенча бары тик Татарстан Республикасы Конституция судының үзе тарафыннан үз утырышында гына бирелә. Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләп үткәнчә, рәсми аңлатма, күрсәтелгән Законның 68 статьясы белән үзара бәйләнештә әлеге норманың мәгънәсе буенча, суд карарын гади кабатлау гына була алмый һәм тиешле норматив хокукый актның конституциячеллеген Татарстан Республикасы Конституция суды башкарган тикшерү чикләреннән чыкмаска тиеш (2001 елның 4 октябрендәге 5-О номерлы, 2005 елның 14 декабрендәге 11-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Конституция Суды рәсми аңлатма бирү турындагы үтенечнамә, әгәр анда бирелгән сораулар карарны асылда ничек тә булса өстәмә аңлатуны яисә яңа хокукый позицияләр формалаштыруны таләп итмәсә, карала алмый дип шулай ук күрсәткән иде (2010 елның 20 апрелендәге 593-О-Р номерлы, 2013 елның 24 сентябрендәге 1270-О-Р номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 1928-О-Р номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Татарстан Республикасы Конституция суды 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карарында шуны күрсәтте: социаль ипотека программасында катнашырга дәгъва итүче граждан һәм аның гаиләсе әгъзалары, Кагыйдәләрнең 2 пунктындагы 2.5 пунктчасы мәгънәсе буенча аларның гаиләсе әгъзасы булган һәм шул ук торак урында яшәүче (теркәлгән) затның милек хокукындагы торак урынында яшәгән (теркәлгән) очракта, әлеге

гаиләнең бер әгъзасына, милекчене кертеп, туры килә торган торак урыннарның гомуми мәйданын хисаплау бергә яшәүче гаилә әгъзалары санына пропорциональ рәвештә, аларның файдалану һәм (яки) милек хокукындагы бөтен торак урыннарының җыелма мәйданыннан чыгып башкарыла.

Бөтен торак урыннарның җыелма мәйданын исәпкә алу кирәклегенә сылтама биреп, Татарстан Республикасы Конституция суды, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәгъва итүче гаиләнең мохтаҗлыгын бәяләгәндә, мондый гаиләнең милкендә дә, эш итүендә (файдалануында) да булган барлык торак урыннарны исәпкә алырга кирәк дигәннән чыгып эш итте. Башка сүзләр белән әйткәндә, карала торган үтенечнамәдә куелган мәсьәләгә карата бу шуны аңлата: социаль ипотека программасы буенча торак урын алуга дәгъва итүче гаилә башка зат (милекче) милкендә булган торак урында яшәү урыны буенча аның гаиләсе әгъзалары сыйфатында теркәлгән очракта социаль ипотека программасы буенча торак урын алуга дәгъва итүче гаиләнең торак мәйдан белән җыелма тәэмин ителеш дәрәҗәсен хисаплау бары тик аларның милекче белән бертигез файдалану хокукы булган торак урыннарны исәпкә алып кына башкарылырга тиеш. Социаль ипотека программасы буенча торак урын алуга дәгъва итүче гаилә әгъзаларының файдалану хокукы булмаган шундый милекченең башка торак урыннары мондый хисаплауны башкарганда исәпкә алынмыйлар.

Шуның белән Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килде: Кагыйдәләрнең 2 пунктындагы 2.2 һәм 2.3 пунктчаларының дәгъвалана торган нигезләмәләре социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәгъва итүче гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган торак урыннарның гомуми мәйданы белән җыелма тәэмин ителеш дәрәҗәсен хисаплаганда аларның милкендә һәм (яки) наем шартнамәсе буенча файдалануында булган бөтен торак урыннар (алардагы өлешләр), шулай ук торак урын милекчесе аларга шул торакта даими яшәү хокукын аларны анда үз гаиләсе әгъзалары буларак кертү (теркәү) юлы белән бирелгән торак урын исәпкә алынырга тиеш дип күздә тоталар. Монда әлеге торак урыннарның гомуми мәйданының җыелма күләме шул торак урыннардан файдаланучы бөтен гаилә әгъзалары санына, торак урын милекчесен кертеп, пропорциональ рәвештә, аларның бергә яшәү (теркәлү) факты булу-булмауга карамастан, хисапланырга тиеш.

Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карарының эчтәлеге һәм мәгънәсе җитәрлек дәрәҗәдә ачык чагылдырылган, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нормаларына тулысынча таяна, һәм алар буенча нинди дә булса хокукый билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карары өстәмә тәфсилләүне яисә аныклауны таләп итми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының

6 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 77 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 28 февралендәге 78-П номерлы карарын рәсми аңлату турында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үтенечнамәсен карауга алудан баш тартырга, чөнки анда куелган мәсьәләне хәл итү өчен әлеге карарны рәсми аңлату таләп ителми.

2. Бу мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Ю.В. Бадановага, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 4-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

5 марта
2019 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению ходатайства гражданки В.М. Омаровой об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 11 июля 2018 года № 14-О**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение обращения гражданки В.М. Омаровой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка В.М. Омарова с ходатайством об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 11 июля 2018 года № 14-О, которым заявительнице было отказано в принятии к рассмотрению жалобы на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 2, 3 и 6 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат» (далее — Порядок), названным постановлением в целом, а также абзацем первым пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 «О порядке опубликования и вступления в силу постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан».

В своем обращении она просит разъяснить определение Конституционного суда Республики Татарстан от 11 июля 2018 года № 14-О и ответить на следующие вопросы:

— обязаны ли организации, предоставляющие населению жилищно-коммунальные услуги, при представлении ими информации с помощью соответствующих документов подтверждать ее применимость (относимость) по отношению к конкретному гражданину;

— признана ли оспоренная норма не содержащей неопределенности в вопросе ее соответствия Конституции Республики Татарстан в том числе с учетом того, что Кабинету Министров Республики Татарстан необходимо устранить пробел в правовом регулировании путем исправления допущенной юридико-технической ошибки, создающей такой пробел.

2. Конституционный суд Республики Татарстан, изучив ходатайство гражданки В.М. Омаровой, не находит оснований для принятия его к рассмотрению.

В соответствии со статьей 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» официальное разъяснение решения Конституционного суда Республики Татарстан дается только самим Конституционным судом Республики Татарстан в своем заседании, в частности, по ходатайству лица, имеющего право на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан. Как уже отмечал Конституционный суд Республики Татарстан, по смыслу данной нормы в ее взаимосвязи со статьей 68 указанного Закона Республики Татарстан официальное разъяснение не может быть простым воспроизведением решения суда и не должно выходить за пределы произведенной Конституционным судом Республики Татарстан проверки конституционности соответствующего нормативного правового акта (определения от 4 октября 2001 года № 5-О, от 14 декабря 2005 года № 11-О и др.).

Конституционный Суд Российской Федерации также неоднократно отмечал, что ходатайство о даче официального разъяснения не может быть рассмотрено, если поставленные в нем вопросы не требуют какого-либо дополнительного истолкования решения по существу или формулирования новых правовых позиций (определения от 20 апреля 2010 года № 593-О-Р, от 24 сентября 2013 года № 1270-О-Р, от 24 декабря 2013 года № 1928-О-Р, от 24 апреля 2018 года № 1110-О-Р и др.).

2.1. Отказывая в принятии к рассмотрению жалобы гражданки В.М. Омаровой, Конституционный суд Республики Татарстан в своем определении от 11 июля 2018 года № 14-О указал, что пунктом 6 Порядка определен механизм взаимодействия, в частности, организаций, предоставляющих населению жилищно-коммунальные услуги по договорам, заключенным непосредственно с гражданами, проживающими в индивидуальном жилищном фонде или многоквартирном жилищном фонде, и территориальных органов Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в муниципальных образованиях или государственного казенного учреждения «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)». Указанные организации на основании подпункта 8 пункта 6 Порядка должны передать в государственное казенное учреждение «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)», в частности, сведения о начислениях за фактически оказанные жилищно-коммунальные услуги, факте отключения коммунальных услуг, факте подключения коммунальных услуг. Тем самым Конституционный суд Республики Татарстан подчеркнул, что оспариваемые нормы в их взаимосвязи и, исходя из их системного толкования, не допускают возможности передачи организацией, предоставляющей населению жилищно-коммунальные услуги по договорам, заключенным непосредственно с гражданами, проживающими в индивидуальном жилищном фонде или многоквартирном жилищном фонде, в уполномоченный орган сведений о фактически не

предоставляемых услугах или услугах, по которым договор с гражданами не заключен. Более того, Конституционный суд Республики Татарстан и ранее в своих решениях отмечал, что по своей правовой природе установленный указанными нормами перечень сведений, передаваемых управляющими организациями в орган, принимающий решение о предоставлении гражданам субсидий-льгот, является исчерпывающим и исключает возможность его произвольного истолкования (определение от 28 декабря 2016 года № 27-О). Конституционный суд Республики Татарстан также указал, что оспариваемый пункт 3 Порядка, регламентирующий обязательность заключения соглашений о порядке взаимодействия организаций-участников, перечисленных в пункте 2, с указанными ведомствами, четко устанавливает, что такое соглашение должно включать в себя ответственность его участников за представление несвоевременной (недостоверной) информации. Тем самым соответствующие сведения должны передаваться в установленный законодательством срок и содержать полную, точную и достоверную информацию.

2.2. Что касается обращения гражданки В.М. Омаровой по порядку вступления в силу нормативных правовых актов Кабинета Министров Республики Татарстан, принятых как по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина, так и по вопросам, затрагивающим права, свободы и обязанности человека и гражданина, то Конституционный суд Республики Татарстан отметил, что формулировка в оспариваемом абзаце первом пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 сентября 2002 года № 524 основана на нормах федерального и республиканского законодательства, регулирующего вопросы опубликования и вступления в силу нормативных правовых актов органов государственной власти.

Таким образом, содержание и смысл определения Конституционного суда Республики Татарстан от 11 июля 2018 года № 14-О выражены исчерпывающим образом, полностью основаны на нормах действующего законодательства Российской Федерации и Конституции Республики Татарстан и какая-либо правовая неопределенность по ним отсутствует. Вследствие этого указанное определение Конституционного суда Республики Татарстан не требует формулирования новых правовых позиций, дополнительной детализации или уточнения.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, пунктом 3 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, статьями 69, 72, 73 и 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению ходатайства гражданки В.М. Омаровой об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 11 июля 2018 года № 14-О.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данному обращению окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке В.М. Омаровой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 7-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 11 июлендәге 14-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка В.М. Омарова үтенечнамәсен карауга алудан баш тарту хакында**

2019 ел
5 март
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка В.М. Омарова мөрәҗәгатен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка В.М. Омарова Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 11 июлендәге 14-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында үтенечнамә белән мөрәҗәгать итте, аның белән мөрәҗәгать итүчегә «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең (алга таба — Тәртип) 2, 3 һәм 6 пунктлары, тулысынча аталган карар, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының 4 пунктындагы беренче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятен карауга алудан баш тартылды.

Үз мөрәҗәгатендә ул Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 11 июлендәге 14-О номерлы билгеләмәсен аңлатуны һәм түбәндәге сорауларга җавап бирүне сорый:

— халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтә торган оешмалар тиешле документлар белән мәгълүмат тапшырганда аның конкрет граждан мөнәсәбәтендә кулланылуын (кагылышлы булуын) расларга тиешме;

— дәгъва белдерелгән нормада Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк дип шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый җайга салудагы җитешсезлекне мондый кимчелекне тудырган юридик-техник хатаны төзәтү юлы белән бетерергә тиеш булуын исәпкә алып танылганмы.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды гражданка

В.М. Омарова үтенечнамәсен өйрәнеп, аны карауга алу өчен нигезләр тапмый.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карарына рәсми аңлатма, аерым алганда, Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия затның үтенечнамәсе буенча бары тик Татарстан Республикасы Конституция судының үзе тарафыннан үз утырышында гына бирелә. Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләп үткәнчә, рәсми аңлатма, күрсәтелгән Законның 68 статьясы белән үзара бәйләнештә әлеге норманың мәгънәсе буенча, суд карарын гади кабатлау гына була алмый һәм тиешле норматив хокукый актның конституциячеллеген Татарстан Республикасы Конституция суды башкарган тикшерү чикләреннән чыкмаска тиеш (2001 елның 4 октябрендәге 5-О номерлы, 2005 елның 14 декабрендәге 11-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Конституция Суды шулай ук берничә тапкыр рәсми аңлатма бирү турындагы үтенечнамә, әгәр анда бирелгән сораулар карарны асылда ничек тә булса өстәмә аңлатуны яисә яңа хокукый позицияләр формалаштыруны таләп итмәсә, карала алмый дип билгеләгән иде (2010 елның 20 апрелендәге 593-О-Р номерлы, 2013 елның 24 сентябрендәге 1270-О-Р номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 1928-О-Р номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 1110-О-Р номерлы һ.б. билгеләмәләр).

2.1. Гражданка В.М. Омарова шикаятен карауга алудан баш тартып, Татарстан Республикасы Конституция суды үзенең 2018 елның 11 июлендәге 14-О номерлы билгеләмәсендә шуны күрсәтте: Тәртипнең 6 пункты белән, аерым алганда, индивидуаль торак фондта яки күпфатирлы торак фондта яшәүче граждannар белән турыдан-туры төзелгән килешүләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль берәмлекләрдәге территориаль органнарының яки «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең хезмәттәшлек итү механизмы билгеләнгән. Күрсәтелгән оешмалар Тәртипнең 6 пунктындагы 8 пунктчасы нигезендә «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә, аерым алганда, гамәлдә күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр өчен хисапланган түләүләр, коммуналь хезмәтләрне өзү факты, коммуналь хезмәтләрне тоташтыру факты турында мәгълүмат тапшырырга тиеш. Шуның белән Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъвалана торган нормалар үзара бәйләнештә һәм аларны системалы аңлатудан чыгып, индивидуаль торак фондта яки күпфатирлы торак фондта яшәүче гражданнар белән турыдан-туры төзелгән килешүләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешманың вәкаләтле органга гамәлдә күрсәтелми торган хезмәтләр яки гражданнар белән килешү төзелмәгән хезмәтләр турында мәгълүматлар тапшыру мөмкинлегенә юл куймыйлар дип ассызыклады. Өстәвенә,

Татарстан Республикасы Конституция суды элегрәк тә үз карарларында үзенең хокукый табигате буенча гражданнарга ташлама-субсидияләр бирү турында карар кабул итә торган органга идарәче оешмалар тапшыра торган күрсәтелгән нормалар белән билгеләнгән мәгълүматлар исемлеге тулы һәм аны иркле аңлату мөмкинлегенә юл куелмаган дип билгеләп үткән иде (2016 елның 28 декабрендәге 27-О номерлы билгеләмә). Татарстан Республикасы Конституция суды шулай ук Тәртипнең 2 пунктында саналган катнашучы оешмаларның күрсәтелгән ведомстволар белән хезмәттәшлек итү тәртибе турында килешүләр төзү тиешлеген регламентлаштыручы дәгъвалана торган 3 пункты андый килешүдә катнашучыларның үз вакытында булмаган (ышанычсыз) мәгълүмат тапшырган өчен җаваплы булуын ачык билгеле дип күрсәтте. Шуның белән тиешле мәгълүматлар законнарда билгеләнгән срокта тапшырылырга һәм тулы, төгәл һәм дөрес мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

2.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча да, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы мәсьәләләр буенча да кабул ителгән норматив хокукый актларының үз көченә керү тәртибе буенча гражданка В.М. Омарова мөрәҗәгатенә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карарының 4 пунктындагы дәгъвалана торган беренче абзацындагы тәгъбир дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе мәсьәләләрен җайга сала торган федераль һәм республика законнары нормаларына нигезләнгән дип билгеләп үтте.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 11 июлендәге 14-О номерлы билгеләмәсенең эчтәлеге һәм мәгънәсе җитәрлек дәрәҗәдә ачык чагылдырылган, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нормаларына тулысынча таяна һәм алар буенча нинди дә булса хокукый билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән билгеләмәсе яңа хокукый позицияләр формалаштыруны, өстәмә тәфсилләүне яисә аныклауны таләп итми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 69, 72, 73 һәм 77 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судының 2018 елның 11 июлендәге 14-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка В.М. Омарова үтенечнамәсен карауга алудан баш тартырга.

2. Бу мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка В.М. Омаровага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 7-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Д.А. Минапова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 33 Земельного кодекса Республики Татарстан (в редакции, действовавшей до вступления в силу Закона Республики Татарстан от 22 декабря 2018 года № 111-ЗРТ)**

5 марта
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина Д.А. Минапова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин Д.А. Минапов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 33 Земельного кодекса Республики Татарстан (в редакции, действовавшей до вступления в силу Закона Республики Татарстан от 22 декабря 2018 года № 111-ЗРТ) (далее также — Земельный кодекс Республики Татарстан).

Оспариваемой нормой Земельного кодекса Республики Татарстан предусмотрено, что гражданам, которые зарегистрированы по месту постоянного проживания в городских поселениях, земельные участки, находящиеся в собственности Республики Татарстан или муниципальной собственности, для ведения личного подсобного хозяйства в соответствии с федеральным законодательством предоставляются при наличии свободных земельных участков.

Как следует из обращения и приложенных к нему копий документов, гражданин Д.А. Минапов проживает в городе Казани, является инвалидом третьей группы и в соответствии с частью шестнадцатой статьи 17 Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» обладает правом на первоочередное получение земельных участков для индивидуального жилищного строительства, ведения подсобного хозяйства и садоводства.

В целях реализации своего права, предусмотренного федеральным законодательством, он неоднократно обращался в Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани, который отказал ему в предоставлении земельного участка. По утверждению заявителя, отказ связан с тем, что в силу обжалуемого пункта 2 статьи 33 Земельного кодекса Республики Татарстан гражданам, которые зарегистрированы по месту постоянного проживания в городских поселениях, земельные участки, находящиеся в собственности Республики Татарстан или муниципальной собственности, для ведения личного подсобного хозяйства предоставляются только при

наличии свободных земельных участков. А для граждан, которые зарегистрированы по месту постоянного проживания в сельских поселениях, Земельный кодекс Республики Татарстан не предусматривает в качестве условия предоставления им земельных участков наличие свободных земельных участков (пункт 1 статьи 33).

Тем самым, по его мнению, Земельный кодекс Республики Татарстан устанавливает дискриминационное положение, вводя различие в условиях реализации права на получение земельного участка в зависимости от места регистрации граждан (в городских или сельских поселениях), ставит их в неравное положение, чем нарушает его конституционные права.

На основании изложенного гражданин Д.А. Минапов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 2 статьи 33 Земельного кодекса Республики Татарстан не соответствующим статьям 27, 28 (части первая и вторая), 30, 54 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

2. По смыслу части второй статьи 46 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан в процессе конституционного судопроизводства проверяет конституционность действующих нормативных правовых актов. Проверка конституционности актов, которые были отменены или утратили силу к началу или в период рассмотрения дела в Конституционном суде Республики Татарстан, не допускается (определения Конституционного суда Республики Татарстан от 27 февраля 2010 года № 3-О, от 17 сентября 2014 года № 15-О и от 6 февраля 2017 года № 6-О).

Законом Республики Татарстан от 22 декабря 2018 года № 111-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан» оспариваемая гражданином Д.А. Минаповым норма Земельного кодекса Республики Татарстан признана утратившей силу. Вышеназванный Закон Республики Татарстан официально опубликован 24 декабря 2018 года на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU) и вступил в силу.

Как отметил Конституционный Суд Российской Федерации, отмена нормативного правового акта самим принявшим этот акт органом государственной власти с очевидностью свидетельствует о том, что такой акт расценивается им как более не подлежащий действию, при этом мотивы, которыми руководствуется данный орган государственной власти, не имеют существенного значения для целей конституционного судопроизводства (Определение от 4 июня 2013 года № 882-О).

Таким образом, утративший силу обжалуемый заявителем пункт 2 статьи 33 Земельного кодекса Республики Татарстан не может быть предметом рассмотрения в Конституционном суде Республики Татарстан в порядке конституционного судопроизводства, а жалоба гражданина Д.А. Минапова не является допустимой.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 2 части первой и частью второй статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73, 100 и 101

Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Д.А. Минапова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 2 статьи 33 Земельного кодекса Республики Татарстан (в редакции, действовавшей до вступления в силу Закона Республики Татарстан от 22 декабря 2018 года № 111-ЗРТ), поскольку жалоба заявителя в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину Д.А. Минапову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 8-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Җир кодексының (2018 елның 22 декабрендәге 111-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) 33 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
5 март
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Д.Ә. Минапов Татарстан Республикасы Җир кодексының (2018 елның 22 декабрендәге 111-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Җир кодексы) 33 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Җир кодексының дәгъвалана торган нормасы белән шәһәр җирлекләрендә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре федераль законнар нигезендә ярдәмче шәхси хуҗалык алып бару өчен буш җир кишәрлекләре булганда бирелә дип билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Д.Ә. Минапов Казан шәһәрендә яши, ул өченче төркем инвалиды һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы уналтынчы өлеше нигезендә индивидуаль торак төзелеше, ярдәмче хуҗалык алып бару һәм бакчачылык белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлекләрен беренче чиратта алу хокукына ия.

Үзенең федераль законнарда каралган хокукын гамәлгә ашыру максатында ул Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән, ләкин җир кишәрлеге бирүдән аңа баш тартканнар. Мөрәҗәгать итүче раславынча, баш тарту шуңа бәйле: Татарстан Республикасы Җир кодексының 33 статьясындагы дәгъва белдерелә торган 2 пункты нигезендә шәһәр җирлекләрендә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль

милектәге җир кишәрлекләре ярдәмче шәхси хуҗалык алып бару өчен бары тик буш җир кишәрлекләре булганда гына бирелә. Ә авыл җирлекләрендә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар өчен Татарстан Республикасы Җир кодексы аларга җир кишәрлекләре бирү шарты итеп буш җир кишәрлекләре булуны күздә тотмый (33 статьяның 1 пункты).

Шуның белән, аның фикеренчә, Татарстан Республикасы Җир кодексы гражданнарның теркәлү урынына (шәһәр яки авыл җирлекләрендә) бәйле рәвештә җир кишәрлеге алу хокукын гамәлгә ашыру шартларына аерма кертеп, дискриминацион нигезләмә билгели, аларны тигезсез хәлгә куя, бу аның конституциячел хокукларын боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Д.Ә. Минапов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Җир кодексының 33 статьясындагы 2 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 27, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 30, 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлешенең мәгънәсе буенча Татарстан Республикасы Конституция суды конституциячел суд эшләрен башкарганда гамәлдәге норматив хокукый актларның конституциячеллеген тикшерә. Татарстан Республикасы Конституция судында эш карала башлаганчы яки аны карау чорында юкка чыгарылган яисә үз көчен югалткан актларның конституциячеллеген тикшерү мөмкин түгел (Татарстан Республикасы Конституция судының 2010 елның 27 февралендәге 3-О номерлы, 2014 елның 17 сентябрендәге 15-О номерлы һәм 2017 елның 6 февралендәге 6-О номерлы билгеләмәләре).

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 декабрендәге 111-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Җир кодексының гражданин Д.Ә. Минапов дәгъва белдерә торган нормасы үз көчен югалткан дип танылган. Югарыда аталган Татарстан Республикасы Законы 2018 елның 24 декабрендә рәсми рәвештә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыккан һәм үз көченә кергән.

Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, норматив хокукый актны әлеге актны кабул иткән дәүләт хакимияте органы тарафыннан гамәлдән чыгару мондый актның гамәлдә булырга тиеш булмаган буларак бәяләнүен ачык күрсәтә, шул ук вакытта әлеге дәүләт хакимияте органы таяна торган сәбәпләр конституциячел суд эшчәнлеге максатлары өчен әһәмиятле түгел (2013 елның 4 июнендәге 882-О номерлы Билгеләмә).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Җир кодексының 33 статьясындагы мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган үз көчен югалткан 2 пункты Татарстан Республикасы Конституция судында конституциячел суд эшчәнлеге тәртибендә ка-

рау предметы була алмый, ә гражданин Д.Ә. Минапов шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына һәм икенче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының (2018 елның 22 декабрендәге 111-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) 33 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүченең шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Д.Ә. Минаповка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 8-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки В.М. Омаровой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 3 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат»**

18 марта 2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Э.М. Мустафиной, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки В.М. Омаровой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка В.М. Омарова на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 3 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 (далее также — Порядок).

Согласно оспариваемому абзацу шестому пункта 3 Порядка в соглашении, на основании которого осуществляется взаимодействие министерств, ведомств и других организаций (далее — организаций-участников) с Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан (его территориальными органами) или с государственным казенным учреждением «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» (его отделениями), должна быть определена ответственность участников соглашения за представление несвоевременной (недостоверной) информации, повлекшей за собой необоснованные денежные выплаты гражданам.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является инвалидом, состоит на учете в отделении № 16 государственного казенного учреждения «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» в Верхнеуслонском муниципальном районе Республики Татарстан (далее — РЦМП) и с 1 февраля 2014 года стала получателем субсидии-льготы на оплату жилого помещения и коммунальных услуг. С декабря 2015 года предоставление ей субсидии-льготы было приостановлено в связи с неуплатой услуги по вывозу твердых бытовых отходов. Соответствующая информация поступила в РЦМП от общества с ограниченной ответственностью «ЭкоАвтоТрейд».

Решением Верхнеуслонского районного суда Республики Татарстан, оставленным без изменения апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан, в удовлетворении исковых требований прокурору, действовавшему в интересах гражданки В.М. Омаровой, о признании незаконными действий, выразившихся в приостановлении предоставления субсидии-льготы на оплату жилья и коммунальных услуг, было отказано. Определением судьи Верховного суда Республики Татарстан в передаче кассационной жалобы для рассмотрения в судебном заседании кассационной инстанции Верховного суда Республики Татарстан также было отказано.

Гражданка В.М. Омарова указывает, что постановления судов общей юрисдикции основаны на оспариваемом пункте 3 Порядка. Исходя из данной нормы, в соглашении, на основании которого осуществляется взаимодействие организаций-участников, должна быть определена ответственность участников соглашения за представление только той несвоевременной (недостоверной) информации, которая повлекла за собой необоснованные денежные выплаты гражданам. Соответственно, как она отмечает, за представление несвоевременной (недостоверной) информации, которая повлекла за собой необоснованные невыплаты гражданам, в соглашении ответственность не определяется.

Таким образом, заявительница считает, что оспариваемая норма, устанавливая обязательность определения в соглашении ответственности его участников не за все случаи представления несвоевременной (недостоверной) информации, а только той, которая повлекла за собой необоснованные денежные выплаты гражданам, нарушает ее конституционные права, в том числе на социальное обеспечение, гарантированное Конституцией Республики Татарстан.

На основании изложенного гражданка В.М. Омарова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать абзац шестой пункта 3 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат», не соответствующим статьям 2, 13, 18 (часть первая), 28 (часть первая) и 49 Конституции Республики Татарстан.

2. Согласно части первой статьи 100 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» правом на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан с жалобой на нарушение конституционных прав и свобод обладают граждане, права и свободы которых нарушены законом Республики Татарстан, нормативными правовыми актами Президента Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан, органов местного самоуправления, и их объединения.

При этом статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» установлено, что жалоба на нарушение законом Республики Татарстан или иным нормативным правовым актом конституционных прав и свобод допустима, если закон или иной нормативный правовой акт затрагивает конституционные права и свободы граждан; закон или иной нормативный правовой акт применен или подлежит применению в конкретном деле, рассмотрение которого завершено или начато в суде или ином органе.

Порядок информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденный постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20, регламентирует информационное взаимодействие министерств, ведомств и других организаций с применением интегрированных информационных технологий предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат в Республике Татарстан с целью обеспечения оперативного предоставления гражданам жилищно-коммунальных субсидий и ежемесячных денежных выплат.

Взаимодействие организаций-участников согласно пункту 3 Порядка осуществляется на основании соглашений, заключенных с Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан (его территориальными органами) или с государственным казенным учреждением «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» (его отделениями), в которых должны быть закреплены конкретные положения, направленные на определение непосредственных участников информационного взаимодействия, порядка и сроков передачи необходимой информации, ответственности за представление несвоевременной (недостоверной) информации, и иные положения. По своей правовой природе пункт 3 Порядка направлен на регламентацию механизма взаимодействия конкретных организаций-участников, на определение формы и содержания такого взаимодействия и, следовательно, не подлежит применению в деле гражданки В.М. Омаровой в указанном ею аспекте.

Таким образом, оспариваемое положение не затрагивает конституционных прав и свобод заявительницы, в связи с чем жалоба не отвечает критериям допустимости, установленным статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», и на этом основании не может быть принята к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

Из содержания жалобы следует, что гражданка В.М. Омарова, формально оспаривая конституционность рассматриваемой нормы, фактически выражает несогласие с действиями и решениями правоприменительных органов, оценка законности и обоснованности которых не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции

Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки В.М. Омаровой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 3 Порядка информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат», поскольку жалоба не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми она признается допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке В.М. Омаровой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 9-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең 3 пунктындагы алтынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка В.М. Омарова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
18 март
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка В.М. Омарова шикаятен алдан өйрәнгән судья Э.М. Мостафина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка В.М. Омарова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3 пунктындагы алтынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Тәртипнең 3 пунктындагы дәгъвалана торган алтынчы абзацы буенча министрлыклар, ведомстволар һәм башка оешмаларның (алга таба — катнашучы оешмалар) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (аның территориаль органнары) яки «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (аның бүлекләре) белән хезмәттәшлек итүе нигезләнгән килешүдә гражданнарга нигезсез акчалата түләүләр бирүне китереп чыгарган үз вакытында булмаган (ышанычсыз) мәгълүмат тапшырган өчен килешүдә катнашучыларның җаваплылыгы билгеләнергә тиеш.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — инвалид, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районындагы 16 номерлы бүлегендә (алга таба — РМЯҮ) исәптә тора һәм 2014 елның 1 февраленнән торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия ала. Каты

көнкүреш калдыкларын чыгару буенча торак-коммуналь хезмәт өчен түләмәү сәбәпле, 2015 елның декабреннән аңа ташлама-субсидияне бирү туктатып торылган. Тиешле мәгълүмат РМЯҮгә «ЭкоАвтоТрейд» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән килгән.

Татарстан Республикасы Югары Ослан район судының Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карары белән гражданка В.М. Омарова мәнфәгатьләрендә эш иткән прокурорга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия бирү туктатылып торуда чагылган гамәлләрне законсыз дип тану турындагы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган. Татарстан Республикасы Югары суды судьясы билгеләмәсе белән кассация шикаятен Татарстан Республикасы Югары судының кассация инстанциясе утырышында карауга тапшырудан шулай ук баш тартылган.

Гражданка В.М. Омарова гомуми юрисдикция судлары карарлары Тәртипнең дәгъва белдерелә торган 3 пунктына нигезләнгән дип күрсәтә. Әлеге нормадан чыгып, катнашучы оешмаларның хезмәттәшлек итүе нигезләнгән килешүдә гражданнарга нигезсез акчалата түләүләр бирүне генә китереп чыгарган үз вакытында булмаган (ышанычсыз) мәгълүмат тапшырган өчен килешүдә катнашучыларның җаваплылыгы билгеләнергә тиеш. Шуңа бәйле рәвештә, ул билгеләп үткәнчә, гражданнарга нигезсез түләмәүне китереп чыгарган үз вакытында булмаган (ышанычсыз) мәгълүмат тапшырган өчен килешүдә җаваплылык билгеләнми.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерелә торган норма, килешүдә катнашучыларның үз вакытында булмаган (ышанычсыз) мәгълүмат тапшыруның барлык очраклары өчен түгел, ә бары тик гражданнарга нигезсез акчалата түләүләр бирүне китереп чыгарганы өчен генә җаваплы булуларын мәҗбүри билгеләү кирәклеген күрсәтеп, аның конституциячел хокукларын, шул исәптән Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнгән социаль тәэминатка хокукын боза дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка В.М. Омарова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең 3 пунктындагы алтынчы абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 18 (беренче өлеш), 28 (беренче өлеш) һәм 49 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең бозылуына карата шикаять белән Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Ми-

нистрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән шул билгеләнгән: Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибе гражданнарга торак-коммуналь субсидияләрне һәм айлык акчалата түләүләрне оператив бирүне тәэмин итү максатында министрлыклар, ведомстволар һәм башка оешмаларның Татарстан Республикасында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирүдә интеграль мәгълүмат технологияләрен кулланып, мәгълүмати хезмәттәшлек итүен регламентлаштыра.

Катнашучы оешмаларның хезмәттәшлек итүе Тәртипнең 3 пункты буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (аның территориаль органнары) яки «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (аның бүлекләре) белән төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла, аларда мәгълүмати хезмәттәшлек итүдә турыдан-туры катнашучыларны, кирәкле мәгълүматны тапшыру тәртибен һәм срокларын, вакытында булмаган (ышанычсыз) мәгълүмат биргән өчен җаваплылык билгеләүгә юнәлгән конкрет нигезләмәләр һәм башка нигезләмәләр беркетелергә тиеш. Үзенең хокукый табигате буенча Тәртипнең 3 пункты конкрет катнашучы оешмаларның хезмәттәшлек итү механизмын регламентлаштыруга, мондый хезмәттәшлек итүнең рәвешен һәм эчтәлеген билгеләүгә юнәлдерелгән һәм, димәк, гражданка В.М. Омарова эшендә ул күрсәткән аспектта кулланылырга тиеш түгел.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган нигезләмә мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылмый, шуңа бәйле рәвештә шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән билгеләнгән бирелү мөмкинлеге критерийларына җавап бирми һәм шуның нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга кабул ителә алмый.

Шикаять эчтәлегеннән аңлашылганча, гражданка В.М. Омарова карала торган норманың конституциячеллегенә формаль дәгъва белдереп, асылда хокук куллану органнарының гамәлләре һәм карарлары белән килешмәвен белдерә, аларның законлы һәм

нигезле булу-булмавын бәяләү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең 3 пунктындагы алтынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка В.М. Омарова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка В.М. Омаровага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 9-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

16 апреля
2019 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Д.А. Минапова на нарушение его конституционных прав и свобод статьей 32 Земельного кодекса Республики Татарстан**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Ф.Р. Волковой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина Д.А. Минапова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин Д.А. Минапов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод статьей 32 Земельного кодекса Республики Татарстан.

Оспариваемая норма регулирует вопросы предоставления земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в собственность граждан и юридических лиц, а также устанавливает случаи предоставления таких земельных участков бесплатно.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданин Д.А. Минапов является инвалидом третьей группы и в соответствии с частью шестнадцатой статьи 17 Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» в редакции, действовавшей до дня вступления в силу Федерального закона от 29 июля 2017 года № 217-ФЗ «О ведении гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации» (далее также — Федеральный закон «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации»), ему предоставляется право на первоочередное получение земельных участков для ведения подсобного и дачного хозяйства и садоводства.

С целью получения земельного участка заявитель неоднократно обращался в Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани. Однако в предоставлении земельного участка ему было отказано со ссылкой на отсутствие в Республике Татарстан нормативной правовой базы, регулирующей порядок предоставления земельных участков инвалидам.

Между тем, как указывает гражданин Д.А. Минапов, Министерство труда и социальной защиты Российской Федерации в своем ответе на его обращение сообщило, что в соответствии со статьей 5 Федерального закона «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» органы государственной власти субъектов

Российской Федерации в области социальной защиты и социальной поддержки инвалидов вправе предоставлять дополнительные меры социальной поддержки за счет средств бюджетов субъектов Российской Федерации.

По мнению гражданина Д.А. Минапова, принимая Земельный кодекс Республики Татарстан и устанавливая в его статье 32 случаи предоставления земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в собственность граждан и юридических лиц бесплатно, республиканский законодатель обязан был принять во внимание часть шестнадцатую статьи 17 Федерального закона «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации», то есть внести в Земельный кодекс Республики Татарстан положение о предоставлении инвалиду права на первоочередное получение земельных участков для ведения подсобного хозяйства и садоводства.

Однако, как отмечает заявитель, Земельный кодекс Республики Татарстан не предусматривает такого права инвалидов, чем ограничивает право инвалидов и семей, имеющих в своем составе инвалидов, на первоочередное получение земельных участков для ведения подсобного хозяйства и садоводства.

На основании изложенного гражданин Д.А. Минапов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать статью 32 Земельного кодекса Республики Татарстан не соответствующей статьям 27, 28 (части первая и вторая), 30, 54 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

2. Земельный кодекс Российской Федерации в качестве одного из основных принципов земельного законодательства установил принцип платности, согласно которому любое использование земли осуществляется за плату, за исключением случаев, предусмотренных федеральными законами и законами субъектов Российской Федерации (подпункт 7 пункта 1 статьи 1).

Федеральным законом от 23 июня 2014 года № 171-ФЗ «О внесении изменений в Земельный кодекс Российской Федерации и отдельные законодательные акты Российской Федерации», вступившим в силу с 1 марта 2015 года, случаи бесплатного предоставления земельного участка, находящегося в государственной или муниципальной собственности, гражданину или юридическому лицу в собственность установлены в статье 39.5 Земельного кодекса Российской Федерации. При этом непосредственно сам Земельный кодекс Российской Федерации не предусматривает в качестве такого случая предоставление на безвозмездной основе земельного участка для ведения подсобного хозяйства и садоводства инвалидам и семьям, имеющим в своем составе инвалидов.

В статье 17 Федерального закона «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» содержится норма о праве инвалидов и семей, имеющих в своем составе инвалидов, на первоочередное получение земельных участков для индивидуального жилищного строительства, ведения подсобного хозяйства и садоводства (часть шестнадцатая). Вместе с тем из наименования указанной статьи «Обеспечение инвалидов жильем» данного Федерального закона

следует, что она регулирует способы реализации права инвалидов и их семей на улучшение жилищных условий, в том числе в рамках получения ими этой социальной гарантии через предоставление земельных участков. При этом бесплатное предоставление земельных участков не предусмотрено.

Возможность предоставления земельных участков отдельным категориям граждан, включая инвалидов, в собственность бесплатно в силу подпункта 7 статьи 39.5 Земельного кодекса Российской Федерации может быть предусмотрена законами субъектов Российской Федерации.

В Республике Татарстан порядок и правила предоставления земельных участков, находящихся в собственности Республики Татарстан или муниципальной собственности, гражданам или юридическим лицам определяются Земельным кодексом Российской Федерации (пункт 2 статьи 31 Земельного кодекса Республики Татарстан). Норма о предоставлении земельных участков в собственность граждан и юридических лиц, в том числе и бесплатно, нашла свое развитие в статье 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, в которой законодатель, действуя в рамках своих дискреционных полномочий, закрепил порядок предоставления в собственность земельных участков на территории Республики Татарстан гражданам и юридическим лицам бесплатно в случаях, предусмотренных Земельным кодексом Российской Федерации, федеральными законами, данным Кодексом и иными законами Республики Татарстан (абзац второй пункта 1 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан).

Отсутствие в статье 32 Земельного кодекса Республики Татарстан указания на инвалидов в числе лиц, которым предоставлена возможность бесплатного получения земельного участка, находящегося в государственной или муниципальной собственности, само по себе не может рассматриваться как нарушающее конституционные права и свободы граждан, в том числе и заявителя, поскольку предоставление такой возможности выступает в качестве дополнительной меры социальной поддержки, установление которой является правом, а не обязанностью Республики Татарстан. Реализация такого права осуществляется за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации и зависит от имеющихся на данном этапе социально-экономического развития его финансовых и иных материальных возможностей. Такой вывод согласуется и с позицией Конституционного Суда Российской Федерации, который неоднократно указывал, что Конституция Российской Федерации не гарантирует бесплатное предоставление земельных участков (определения от 15 января 2009 года № 105-О-О, от 24 февраля 2011 года № 163-О-О и др.).

Таким образом, оспариваемая норма не содержит неопределенности в указанном заявителем аспекте, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданина Д.А. Минапова не является допустимой. Расширение же перечня категорий

граждан, которым предоставлено вышеназванное право, на чем фактически настаивает заявитель, предполагает внесение изменений в действующее земельное законодательство, что входит в компетенцию законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Д.А. Минапова на нарушение его конституционных прав и свобод статьей 32 Земельного кодекса Республики Татарстан.
2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
3. Копию настоящего Определения направить гражданину Д.А. Минапову и в Государственный Совет Республики Татарстан.
4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 11-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
16 апрель
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Д.Ә. Минапов Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъва белдерелә торган норма дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә бирү мәсьәләләрен җайга сала, шулай ук мондый җир кишәрлекләрен түләүсез бирү очракларын билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Д.Ә. Минапов — өченче төркем инвалиды һәм аңа «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә (алга таба шулай ук — «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон) 17 статьясындагы уналтынчы өлеше нигезендә ярдәмче хуҗалык һәм дача хуҗалыгы алып бару һәм бакчачылык белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлекләрен беренче чиратта алу хокукы бирелә.

Җир кишәрлеген алу максатында шикаять бирүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән. Әмма Татарстан Республикасында инвалидларга җир кишәрлекләре бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый базаның булмавына сылтама белән җир кишәрлеге бирүдән аңа баш тартканнар.

Шул ук вакытта, гражданин Д.Ә. Минапов күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы аның

мөрәҗәгатенә җавабында «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 5 статьясы нигезендә инвалидларны социаль яклау һәм аларга социаль ярдәм өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары хисабына социаль ярдәмнең өстәмә чараларын күрсәтергә хокуклы дип хәбәр иткән.

Гражданин Д.Ә. Минапов фикеренчә, Татарстан Республикасы Җир кодексын кабул итеп һәм аның 32 статьясында дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә түләүсез бирү очракларын билгеләп, республика закон чыгаручысы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясындагы уналтынчы өлешен игътибарга алырга, ягъни Татарстан Республикасы Җир кодексына ярдәмче хуҗалык алып бару һәм бакчачылык белән шөгыльләнү өчен инвалидка җир кишәрлекләрен беренче чиратта алу хокукын бирү турындагы нигезләмәне кертергә тиеш иде.

Ләкин, мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, Татарстан Республикасы Җир кодексы инвалидларның андый хокукын күздә тотмый, шуның белән инвалидларның һәм үз составында инвалидлар булган гаиләләрнең ярдәмче хуҗалык алып бару һәм бакчачылык белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлекләрен беренче чиратта алу хокукын чикли.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Д.Ә. Минапов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 27, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 30, 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Җир кодексы җир законнарының төп принципларының берсе буларак түләүле булу принцибын билгели, аның нигезендә җирдән теләсә нинди файдалану, федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очраклардан тыш, акча түләп гамәлгә ашырыла (1 статьяның 1 пунктындагы 7 пунктчасы).

2015 елның 1 мартыннан үз көченә кергән «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон белән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданга яки юридик затка милеккә түләүсез бирү очраклары Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясында билгеләнгән. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Җир кодексы турыдан-туры үзе мондый очрак буларак ярдәмче хуҗалык алып бару һәм бакчачылык белән шөгыльләнү өчен инвалидларга һәм үз составында инвалидлар булган гаиләләргә түләүсез нигездә җир кишәрлеге бирүне күздә тотмый.

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясында инвалидларның һәм үз составында инвалидлар булган гаиләләрнең индивидуаль торак төзелеше, ярдәмче хуҗалык алып бару һәм бакчачылык белән

шөгыльләнү өчен җир кишәрлекләрен беренче чиратта алу хокукы турында норма бар (уналтынчы өлеш). Шуның белән бергә әлеге Федераль законның күрсәтелгән «Инвалидларны торак белән тәэмин итү» статьясы исеменнән күренгәнчә, ул инвалидларның һәм аларның гаиләләренең торак шартларын яхшыртуга хокукларын гамәлгә ашыру ысулларын җайга сала, шул исәптән аларның әлеге социаль гарантияне җир кишәрлекләрен бирү аша алу кысаларында да. Шул ук вакытта җир кишәрлекләрен түләүсез бирү каралмаган.

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясындагы 7 пунктчасы нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә, инвалидларны да кертеп, җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү мөмкинлеге Россия Федерациясе субъектлары законнары белән каралырга мөмкин.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнарга яки юридик затларга бирү тәртибе һәм кагыйдәләре Россия Федерациясе Җир кодексы белән билгеләнә (Татарстан Республикасы Җир кодексының 31 статьясындагы 2 пункты). Гражданнар һәм юридик затлар милкенә җир кишәрлекләрен шул исәптән түләүсез дә бирү турындагы норма Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясында үсеш алган, анда закон чыгаручы, үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында эш итеп, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга һәм юридик затларга Россия Федерациясе Җир кодексы, федераль законнар, әлеге Кодекс һәм Татарстан Республикасының башка законнары белән каралган очракларда җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү тәртибен беркеткән (Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы).

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясында инвалидларның дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез алу мөмкинлеге бирелгән затлар исәбендә булмавы үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган буларак карала алмый, чөнки андый мөмкинлекне бирү социаль ярдәмнең өстәмә чарасы сыйфатында карала, аны билгеләү Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора. Мондый хокукны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла һәм әлеге социаль-икътисади үсеш этабында булган аның финанс һәм башка материаль мөмкинлекләренә бәйле. Мондый нәтиҗә Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә дә туры килә, ул Россия Федерациясе Конституциясенең җир кишәрлекләрен түләүсез бирүне гарантияләмәве турында берничә мәртәбә искәртте (2009 елның 15 гыйнварындагы 105-О-О номерлы, 2011 елның 24 февралендәге 163-О-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Шулай итеп, дәгъвалана торган нормада мөрәҗәгать итүче күрсәткән аспектта билгесезлек юк, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче

өлешенең 2 пункты нигезендә гражданин Д.Ә. Минапов шикаяте карала алмый. Югарыда аталган хокук бирелгән гражданнар категорияләре исемлеген киңәйтү, мөрәҗәгать итүче шуңа басым ясый да, гамәлдәге җир законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә закон чыгаручы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен карауга алудан баш тартырга.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Д.Ә. Минаповка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 11-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.Д. Шаймардановой на нарушение ее конституционных прав и свобод преамбулой и статьей 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”»**

18 апреля
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Ф.Р. Волковой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки А.Д. Шаймардановой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка А.Д. Шаймарданова на нарушение ее конституционных прав и свобод преамбулой и статьей 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”» (далее также — Закон Республики Татарстан).

Из преамбулы следует, что Законом Республики Татарстан в соответствии с пунктом 4 статьи 7 Федерального закона от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» определяются порядок и условия присвоения звания «Ветеран труда». Статья 1 Закона Республики Татарстан определяет круг лиц, которым присваивается звание «Ветеран труда», а также устанавливает основания для присвоения звания «Ветеран труда» — награждение ведомственными знаками отличия за заслуги в труде (службе), под которыми понимаются ведомственные награды за заслуги в труде (службе) и продолжительную работу (службу) не менее 15 лет в соответствующей сфере деятельности (отрасли экономики), учрежденные федеральными органами исполнительной власти, иными федеральными государственными органами, государственными корпорациями, и награждение которыми осуществлялось в порядке, установленном указанными органами и организациями.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданка А.Д. Шаймарданова не награждена ни одним из знаков отличия, входящих в перечень ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых в Республике Татарстан при присвоении звания «Ветеран труда», хотя она имеет трудовой стаж более 35 лет и в период работы была награждена знаком «Ударник коммунистического труда».

По вопросу присвоения звания «Ветеран труда» она обращалась в органы государственной власти Республики Татарстан, в том числе и в Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан, но ей было отказано ввиду того, что она не подпадает под категории граждан, имеющих право на присвоение этого звания. При этом Государственным Советом Республики Татарстан ей было разъяснено, что установление дополнительных условий и оснований

присвоения звания «Ветеран труда» к предмету регулирования обжалуемого Закона Республики Татарстан не относится.

По мнению гражданки А.Д. Шаймардановой, республиканский законодатель, основываясь только на пункте 4 статьи 7 Федерального закона от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах» (далее также — Федеральный закон «О ветеранах»), не учел в оспариваемом Законе Республики Татарстан положения части третьей статьи 26.3-1 Федерального закона от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» (далее также — Федеральный закон № 184-ФЗ), согласно которым органы государственной власти субъекта Российской Федерации вправе устанавливать за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи для отдельных категорий граждан, в том числе исходя из установленных законами и иными нормативными правовыми актами субъекта Российской Федерации критериев нуждаемости, вне зависимости от наличия в федеральных законах положений, устанавливающих указанное право.

Нарушение своих конституционных прав заявительница усматривает в том, что республиканский законодатель ограничился лишь тем кругом субъектов и оснований для присвоения звания «Ветеран труда», которые предусмотрены в федеральном законодательстве, не учитывая при этом стаж работы на территории Республики Татарстан, трудовой вклад в экономику и промышленный потенциал Татарстана, а также полученные гражданами знаки отличия Республики Татарстан.

На основании изложенного гражданка А.Д. Шаймарданова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать преамбулу и статью 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”» не соответствующими статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (части первая и вторая), 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. В пункте 1 статьи 7 Федерального закона «О ветеранах» установлены общие основания присвоения звания «Ветеран труда» и категории лиц, являющихся ветеранами труда, к числу которых отнесены, в частности, и лица, награжденные ведомственными знаками отличия за заслуги в труде (службе) и продолжительную работу (службу) не менее 15 лет в соответствующей сфере деятельности (отрасли экономики) и имеющие трудовой (страховой) стаж, учитываемый для назначения пенсии, не менее 25 лет для мужчин и 20 лет для женщин. Пункт 4 статьи 7 данного Федерального закона предоставляет субъектам Российской Федерации право определять порядок и условия присвоения звания «Ветеран труда».

Как отметил Конституционный Суд Российской Федерации, установление порядка и условий присвоения звания «Ветеран труда» и, соответственно, определение того, какие знаки отличия в труде подлежат учету для присвоения указанного звания, относится

к компетенции субъектов Российской Федерации (Определение от 21 ноября 2013 года № 1821-О).

Республиканский законодатель, реализуя полномочия, предоставленные ему пунктом 4 статьи 7 Федерального закона «О ветеранах», был вправе самостоятельно определить в обжалуемом Законе Республики Татарстан как перечень ведомственных знаков отличия в труде, учитываемых при присвоении звания «Ветеран труда», так и условия, которым должны соответствовать данные знаки отличия. При этом оспариваемые положения преамбулы и части 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан по своему содержанию и правовому смыслу идентичны положениям, закрепленным в пунктах 1 и 4 статьи 7 указанного Федерального закона.

Из этого следует, что проверка конституционности обжалуемых норм фактически означала бы оценку названных положений федерального законодательства на их соответствие Конституции Республики Татарстан, что в силу статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

Кроме того, обжалуемые гражданкой А.Д. Шаймардановой положения части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан, касающиеся отнесения ведомственных наград к ведомственным знакам отличия в труде, учитываемым при присвоении звания «Ветеран труда», уже являлись предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан. Согласно правовой позиции Конституционного суда Республики Татарстан, неоднократно высказанной им в своих решениях, установленное в части 2 статьи 1 оспариваемого Закона Республики Татарстан условие об отнесении к ведомственным знакам отличия в труде наград центральных органов только тех общественных объединений и организаций, которые участвуют (участвовали) в осуществлении государственных (ведомственных) функций, производно от публично-правовой природы отношений, связанных с присвоением звания «Ветеран труда», поскольку присвоение лицу данного звания влечет возникновение обязанности соответствующего государственного органа по предоставлению ветерану труда мер социальной поддержки, финансируемых за счет средств бюджета (постановление от 25 марта 2014 года № 58-П, определения от 8 апреля 2014 года № 8-О, от 2 июля 2015 года № 5-О).

Относительно доводов заявительницы о том, что в оспариваемом Законе Республики Татарстан законодатель не учел нормы части третьей статьи 26.3-1 Федерального закона № 184-ФЗ о праве органов государственной власти субъекта Российской Федерации устанавливать за счет средств своего бюджета дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи, Конституционный суд Республики Татарстан ранее неоднократно отмечал, что в силу части четвертой данной статьи финансирование таких полномочий не является обязанностью субъекта Российской Федерации, осуществляется при наличии возможности (постановление от 10 июля 2013 года № 54-П, определения от 20 июня 2018 года № 8-О, от 10 сентября 2018 года № 19-О). Тем самым установление таких

мер социальной поддержки и социальной помощи является правом Республики Татарстан, основания и условия их предоставления определяются республикой самостоятельно с учетом имеющихся на данном этапе социально-экономического развития финансовых и иных материальных возможностей.

Таким образом, обжалуемые заявительницей положения преамбулы и статьи 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”» не содержат неопределенности в вопросе о соответствии Конституции Республики Татарстан и согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» данная жалоба не является допустимой.

Разрешение же вопроса о расширении перечня лиц, которым присваивается звание «Ветеран труда», равно как и оценка обоснованности решений, принятых правоприменительными органами при рассмотрении обращений гражданки А.Д. Шаймардановой, не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.Д. Шаймардановой на нарушение ее конституционных прав и свобод преамбулой и статьей 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 33-ЗРТ «О порядке и условиях присвоения звания “Ветеран труда”», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение постановленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке А.Д. Шаймардановой и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 12-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының преамбуласы һәм 1 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Ә.Д. Шәймәрданова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
18 апрель
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Ә.Д. Шәймәрданова шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Ә.Д. Шәймәрданова «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) преамбуласы һәм 1 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Преамбуладан күренгәнчә, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Законы белән «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары билгеләнә. Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы «Хезмәт ветераны» исеме бирелә торган затлар даирәсен ачыклый, шулай ук «Хезмәт ветераны» исеме бирелү өчен нигезләр билгели — эштәге (хезмәттәге) казанышлар өчен ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнү, аларны федераль башкарма хакимият органнары, башка федераль дәүләт органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә куелган һәм алар белән бүләкләү күрсәтелгән органнар һәм оешмалар билгеләгән тәртиптә башкарылган, эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство бүләкләре дип аңларга кирәк.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документлардан күренгәнчә, гражданка Ә.Д. Шәймәрданова «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә Татарстан Республикасында исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлегенә кергән аерымлык тамгаларының берсе белән дә бүләкләнмәгән, гәрчә аның 35 елдан артык хезмәт стажы булса да һәм ул эш чорында «Коммунистик хезмәт ударнигы» тамгасы белән бүләкләнсә дә.

«Хезмәт ветераны» исемен бирү мәсьәләсе буенча ул Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, шул исәптән

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына да мөрәҗәгать иткән, ләкин әлеге исем бирелү хокукы булган гражданнар категорияләренә кермәве сәбәпле, аңа баш тартканнар. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының җайга салу предметына «Хезмәт ветераны» исеме бирелүнең өстәмә шартларын һәм нигезләрен билгеләү кермәве аңа аңлатылган булган.

Гражданка Ә.Д. Шаймәрданова фикеренчә, республика закон чыгаручысы, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба шулай ук — «Ветераннар турында» Федераль закон) 7 статьясындагы 4 пунктына гына нигезләнеп, дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба шулай ук — 184-ФЗ номерлы Федераль закон) 26.3-1 статьясындагы өченче өлеше нигезләмәләрен исәпкә алмаган, алар буенча Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел.

Мөрәҗәгать итүче үзенең конституциячел хокукларының бозылуын шунда күрә: республика закон чыгаручысы, Татарстан Республикасы территориясендәге эш стажын, Татарстан икътисадына һәм сәнәгать потенциалына хезмәт белән кертелгән өлешне, шулай ук гражданнар алган Татарстан Республикасының аерымлык тамгаларын исәпкә алмыйча, «Хезмәт ветераны» исеме бирелү өчен федераль законнарда каралган субъектлар һәм нигезләр даирәсе белән генә чикләнгән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Ә.Д. Шаймәрданова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының преамбуласын һәм 1 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче һәм икенче өлешләр), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Ветераннар турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пунктында «Хезмәт ветераны» исеме бирелүнең гомуми нигезләре һәм хезмәт ветераннары булган затлар категорияләре билгеләнгән, алар исәбенә, аерым алганда, эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен

ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнгән һәм пенсия билгеләү өчен ирләргә кимендә 25 ел һәм хатын-кызларга кимендә 20 ел итеп исәпләнә торган хезмәт (иминият) стажы булган затлар да керә. Әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 4 пункты Россия Федерациясе субъектларына «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибен һәм шартларын билгеләү хокукын бирә.

Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибен һәм шартларын билгеләү һәм әлеге исем бирү өчен хезмәттәге аерымлыкның кайсы тамгалары исәпкә алынырга тиеш булуын билгеләү Россия Федерациясе субъектлары компетенциясенә керә (2013 елның 21 ноябрендәге 1821-О номерлы Билгеләмә).

Республика закон чыгаручысы «Ветераннар турында» Федераль законның 7 статьясындагы 4 пункты белән үзенә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законында «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлеген дә, әлеге аерымлык тамгалары туры килергә тиешле шартларны да мөстәкыйль билгеләргә хокуклы булган. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Законының преамбуласы һәм 1 статьясындагы 1 өлешенең дәгъвалана торган нигезләмәләре үзләренең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча күрсәтелгән Федераль законның 7 статьясындагы 1 һәм 4 пунктларында беркетелгән нигезләмәләренә тиңдәш.

Моннан чыгып, дәгъвалана торган нормаларның конституциячеллеген тикшерү асылда аталган федераль законнар нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә бәя бирүне аңлатыр иде, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең ведомство бүләкләрен «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исәбенә кертүгә бәйле гражданка Ә.Д. Шәймәрданова тарафыннан дәгъвалана торган нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. Татарстан Республикасы Конституция судының үз карарларында берничә тапкыр әйтелгән хокукый позициясе буенча дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән хезмәттәге ведомство аерымлык тамгаларына дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашучы (катнашкан) иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның үзәк органнары бүләкләрен генә кертү турындагы шарт «Хезмәт ветераны» исеме бирелүгә бәйле мөнәсәбәтләрнең гавами-хокукый табигатеннән килеп чыга, чөнки затка бу исемне бирү тиешле дәүләт органының ветеранга бюджет акчалары исәбеннән финанслана торган социаль ярдәм чараларын күрсәтү йөкләмәсен барлыкка китерә (2014 елның 25 мартындагы 58-П но-

мерлы карар, 2014 елның 8 апрелендәге 8-О номерлы, 2015 елның 2 июлендәге 5-О номерлы билгеләмәләр).

Мөрәҗәгать итүченең дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законында закон чыгаручының Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының үз бюджеты акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын билгеләү хокукы турындагы 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3-1 статьясындагы өченче өлеше нормаларын исәпкә алмавы хакындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды элек берничә тапкыр әлеге статьяның дүртенче өлеше нигезендә мондый вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла дип билгеләп үткән иде (2013 елның 10 июлендәге 54-П номерлы карар, 2018 елның 20 июнендәге 8-О номерлы, 2018 елның 10 сентябрендәге 19-О номерлы билгеләмәләр). Шуның белән социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның мондый чараларын билгеләү Татарстан Республикасы хокукы булып тора, аларны бирү нигезләре һәм шартлары, социаль-икътисади үсешнең әлеге этабында булган финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Шулай итеп, «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының преамбуласы һәм 1 статьясының мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган нигезләмәләрендә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә әлеге шикаять карала алмый.

«Хезмәт ветераны» исеме бирелә торган затлар исемлеген киңәйтү турындагы мәсьәләне хәл итү исә, гражданка Ә.Д. Шәймәрданова мөрәҗәгатьләрен караганда хокук куллану органнары кабул иткән карарларның нигезле булу-булмавын бәяләү кебек, Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары ту-

Казан шәһәре Вахитов район судының 2018 елның 25 сентябрендәге карары белән гражданка И.А. Козлованың Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә карата территорияне планлаштыру проектын раслау өлешендә шикаять белдерелә торган карарны, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирүдән баш тартуны законсыз дип тану турында; җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирүне йөкләү турында административ дәгъвасын канәгатьләндерүдән баш тартылган. Татарстан Республикасы Югары судының административ эшләр буенча суд коллегиясенең 2019 елның 15 гыйнварындагы апелляция билгеләмәсе белән Казан шәһәре Вахитов район суды карары гамәлдән чыгарылган, эш яңадан карауга җибәрелгән.

Мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерелә торган карарда хокукый билгесезлек булуын билгеләп үтә, чөнки Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясындагы 1 пунктының 3 пунктчасы нигезендә дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен аерып алу, шул исәптән сатып алу федераль законнарда билгеләнгән конкрет хәлләргә бәйле аерым очракларда гамәлгә ашырыла. Аның фикеренчә, дәгъвалана торган карарда Татарстан Республикасы Конституциясенең 18, 19 һәм 49 статьяларында каралган хосусый милекнең кагылгысызлыгы гарантияләрен бозарга мөмкинлек бирә торган Россия Федерациясе Җир кодексында күрсәтелгән нигезләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка И.А. Козлова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Әмәт” территориясен планлаштыру проектын раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4666 номерлы карарын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясендә территорияне планлаштыру буенча мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба шулай ук — РФ ШрК) 5 бүлеге тарафыннан җайга салынган. РФ ШрКның 3 статьясындагы 1 һәм 4 өлешләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар әлеге Кодекстан, башка федераль законнардан һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актларыннан тора. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар кабул ителә, алар әлеге Кодекска каршы килергә тиеш түгел.

РФ ШрКның 46 статьясындагы 1 өлеше нигезендә шәһәр округы территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү турында карар шәһәр округының җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге орган инициативасы буенча яисә физик яки юри-

дик затларның территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турындагы тәкъдимнәре нигезендә кабул ителә.

Шулай итеп, «“Әмәт” территориясен планлаштыру проектын раслау турында» 2015 елның 31 декабрендәге 4666 номерлы карарын кабул итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенә федераль законнар белән бирелгән компетенция чикләрендә эш иткән.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче 4666 номерлы карарның конституциячеллегенә формаль рәвештә дәгъва белдереп, фактта «Әмәт» территориясен планлаштыру проекты белән мәктәпкәчә белем бирү объектын урнаштыру планлаштырыла торган өлешендә килешмәвен белдерә. Шул ук вакытта әлеге мәсьәләне хәл итү исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «“Әмәт” территориясен планлаштыру проектын раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4666 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка И.А. Козлова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка И.А. Козловага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 14-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Д.А. Минапова на нарушение его конституционных прав и свобод статьями 6, 7 и 8 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 3-ЗРТ «О государственной поддержке развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан»**

3 июня
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина Д.А. Минапова,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин Д.А. Минапов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод статьями 6, 7 и 8 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 3-ЗРТ «О государственной поддержке развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан).

Оспариваемые заявителем правовые нормы Закона Республики Татарстан устанавливают организационные и финансовые меры государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств в Республике Татарстан (статьи 6 и 7), а также порядок вступления данного Закона Республики Татарстан в силу — со дня его официального опубликования (статья 8).

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданин Д.А. Минапов является инвалидом третьей группы. Заявитель указывает, что в соответствии с частью шестнадцатой статьи 17 Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» инвалидам и семьям, имеющим в своем составе инвалидов, предоставляется право на первоочередное получение земельных участков для индивидуального жилищного строительства, ведения подсобного хозяйства и садоводства.

С целью получения земельного участка он неоднократно обращался в Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани, в предоставлении которого ему было отказано со ссылкой на отсутствие в Республике Татарстан нормативной правовой базы, регулирующей порядок предоставления земельных участков инвалидам.

Вместе с тем, как отмечает гражданин Д.А. Минапов, в ответе Министерства труда и социальной защиты Российской Федерации указано, что правоотношения, связанные с владением, пользованием и распоряжением землей и не урегулированные федеральным законодательством, как, в частности, порядок предоставления земельных участков в первоочередном порядке инвалидам и семьям,

имеющим в своем составе инвалидов, могут быть урегулированы законодательством субъекта Российской Федерации. При этом он считает, что согласно подпункту 7 статьи 39.5 Земельного кодекса Российской Федерации предоставление земельного участка, находящегося в государственной или муниципальной собственности, гражданину или юридическому лицу в собственность бесплатно на основании решения уполномоченного органа осуществляется в том числе в случае предоставления земельного участка отдельным категориям граждан в случаях, предусмотренных законами субъектов Российской Федерации.

В этой связи нарушение своих конституционных прав и свобод оспариваемыми статьями 6 и 7 Закона Республики Татарстан гражданин Д.А. Минапов усматривает в том, что в них устанавливаются организационные и финансовые меры государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств только в отношении тех граждан, которые уже ведут личное подсобное хозяйство, и не учитывается, что развитие личных подсобных хозяйств может осуществляться также путем предоставления земельных участков для этих целей отдельным категориям граждан, в частности инвалидам. Таким образом, он считает, что обжалуемые нормы нарушают конституционные принципы правовой определенности и юридического равенства, а также его конституционные права.

Кроме того, заявитель полагает, что его конституционные права также нарушены предусмотренным статьей 8 оспариваемого Закона Республики Татарстан порядком вступления его в силу. В обоснование своей позиции он ссылается на статью 6 Закона Республики Татарстан от 31 октября 2002 года № 21-ЗРТ «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина», согласно которой нормативные правовые акты Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина вступают в силу через 10 дней после их официального опубликования, если самими актами не установлен иной, более поздний срок вступления их в силу. По его утверждению, оспариваемый Закон Республики Татарстан затрагивает права граждан, и в этой связи он считает, что республиканский законодатель не имел правовых оснований для установления положения о вступлении указанного Закона Республики Татарстан в силу со дня его официального опубликования.

На основании изложенного гражданин Д.А. Минапов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать статьи 6, 7 и 8 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 3-ЗРТ «О государственной поддержке развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан» не соответствующими статьям 13, 24 (часть третья), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая) и 49 Конституции Республики Татарстан.

2. Конституционный суд Республики Татарстан, изучив представленные заявителем материалы, не находит оснований для принятия его жалобы к рассмотрению.

Закон Республики Татарстан, отдельные положения которого оспаривает гражданин Д.А. Минапов, устанавливает меры госу-

дарственной поддержки развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан в целях повышения занятости и улучшения материального положения сельского населения, содействия развитию продовольственного рынка Республики Татарстан, а также определяет полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в области государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств (статья 1).

По своей правовой природе и содержанию обжалуемые правовые положения статей 6 и 7 определяют организационные и финансовые меры государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан и распространяются только на граждан, ведущих личное подсобное хозяйство. Вопросы же предоставления земельных участков гражданам для ведения личного подсобного хозяйства предметом правового регулирования как рассматриваемых норм, так и данного Закона Республики Татарстан в целом не являются.

Из содержания жалобы и приложенных к ней копий документов не следует, что именно указанные нормы послужили безусловным основанием для отказа заявителю в предоставлении земельного участка для ведения личного подсобного хозяйства.

Согласно правовой позиции Конституционного Суда Российской Федерации в случае, если оспариваемый закон затрагивает права и свободы граждан, но оснований полагать, что именно он послужил основанием для отказа в удовлетворении правовых притязаний заявителя в его конкретном деле, не имеется, жалоба не может быть принята Конституционным судом к рассмотрению (определения от 1 декабря 2015 года № 2698-О и от 9 февраля 2016 года № 225-О).

Таким образом, сами по себе обжалуемые положения статей 6 и 7 Закона Республики Татарстан не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права и свободы заявителя, не применялись и не подлежали применению в разрешении его конкретного дела в указанном им аспекте, в связи с чем его жалоба не отвечает критериям допустимости, установленным статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», и на этом основании не может быть принята к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

При таких обстоятельствах дальнейшая оценка конституционности положений статьи 8 Закона Республики Татарстан означала бы ее проверку в порядке абстрактного нормоконтроля, что по жалобе гражданина Конституционный суд Республики Татарстан не вправе делать в силу требований статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан». Наличие подобного рода обстоятельств является основанием для отказа в принятии обращения к рассмотрению в соответствии со статьей 46 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Формально оспаривая конституционность обжалуемых нормативных положений, гражданин Д.А. Минапов фактически ставит перед Конституционным судом Республики Татарстан вопрос о необходимости совершенствования существующего нормативного правового регулирования. Между тем разрешение поставленного

вопроса не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Д.А. Минапова на нарушение его конституционных прав и свобод статьями 6, 7 и 8 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 3-ЗРТ «О государственной поддержке развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявителем вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину Д.А. Минапову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 17-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6, 7 һәм 8 статьялары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
3 июнь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Д.Ә. Минапов «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 6, 7 һәм 8 статьялары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нормалары Татарстан Республикасында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең оештыру һәм финанс чараларын (6 һәм 7 статьялар), шулай ук әлеге Татарстан Республикасы Законының рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керү тәртибен (8 статья) билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Д.Ә. Минаповның өченче төркем инвалидлыгы бар. Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы уналтынчы өлеше нигезендә инвалидларга һәм составында инвалидлар булган гаиләләргә шәхси торак төзелеше, ярдәмче хуҗалык алып бару һәм бакчачылык өчен җир кишәрлекләрен беренче чиратта алу хокукы бирелә.

Җир кишәрлеген алу максатында ул Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән, ләкин, Татарстан Республикасында инвалидларга җир кишәрлекләре бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый базаның булмавын сылтау итеп, мөрәҗәгать кире кагылган.

Шуның белән бергә, гражданин Д.Ә. Минапов билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министр-

лыгы җавабында җир биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү белән бәйле һәм федераль законнар белән җайга салынмаган хокукый мөнәсәбәтләр, аерым алганда, инвалидларга һәм составында инвалидлар булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законнары белән җайга салынырга мөмкин дип күрсәтелгән. Шул ук вакытта ул Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясындагы 7 пунктчасы буенча милкендәге яисә я муниципаль милектәге җир кишәрлеге гражданга я юридик затка милек итеп вәкаләтле органның карары нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда гражданнарның аерым категорияләренә җир кишәрлеге бирелү очрагында түләүсез бирелә дип саный.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин Д.Ә. Минапов Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган 6 һәм 7 статьялары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуын шунда күрә: аларда әлегә кадәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга карата гына дәүләт ярдәменең оештыру һәм финанс чаралары билгеләнә һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү гражданнарның аерым категорияләренә, аерым алганда, инвалидларга әлеге максатларда җир кишәрлекләре бирү юлы белән дә гамәлгә ашырылырга мөмкин икәнлеге исәпкә алынмый. Ул, шулай итеп, шикаять бирелә торган нормалар белән хокукый билгеләнеш һәм юридик тигезлек конституциячел принциплары, шулай ук үзенең конституциячел хокуклары бозыла дип саный.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче шулай ук дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 8 статьясында каралган әлеге Законның үз көченә керү тәртибе белән дә аның конституциячел хокуклары бозылган дип саный. Үз позициясен нигезләүдә ул «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына сылтама ясый, аның нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керәләр, әгәр дә актларның үзләрендә аларның бүтән, соңрак, үз көченә керү вакыты билгеләнгән булмаса.

Аның раславынча, дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законы гражданнарның хокукларына кагыла һәм шуңа бәйле рәвештә ул республика закон чыгаручысының күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүе турындагы нигезләмәне билгеләү өчен хокукый нигезе булмаган дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Д.Ә. Минапов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законының 6, 7 һәм 8 статьяларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 24 (өченче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 49 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган материалларны өйрәнгәннән соң, аның шикаятен карауга алу өчен нигез юк дип саный.

Аерым нигезләмәләренә гражданин Д.Ә. Минапов дәгъва белдерә торган Татарстан Республикасы Законы авыл халкының эш белән тәэмин ителешен арттыру һәм матди хәлен яхшырту, Татарстан Республикасының азык-төлек базарын үстерүгә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгели (1 статья).

6 һәм 7 статьяларның шикаять белдерелә торган хокукый нигезләмәләре үзләренең хокукый табигате һәм эчтәлеге буенча Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең оештыру һәм финанс чараларын билгели һәм бары тик шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга гына кагыла. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга җир кишәрлекләре бирү мәсьәләләре исә карала торган нормаларның да, шулай ук тулаем әлеге Татарстан Республикасы Законының да хокукый җайга салу предметы булып тормый.

Шикаять һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләре эчтәлегеннән күренгәнчә, нәкъ менә күрсәтелгән нормалар мөрәҗәгать итүчегә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлеге бирүдән баш тартуга бернинди шартларсыз нигез булып тормый.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе буенча, дәгъва белдерелә торган закон гражданнарның хокукларына һәм ирекләренә кагылса да, мөрәҗәгать итүченең конкрет эшендә хокукый дәгъваларын канәгатьләндерүдән баш тарту өчен нәкъ менә ул нигез булды дип санау өчен сәбәп булмаса, шикаять Конституция суды тарафыннан карауга алына алмый (2015 елның 1 декабрендәге 2698-О номерлы һәм 2016 елның 9 февралендәге 225-О номерлы билгеләмәләр).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларының шикаять белдерелә торган нигезләмәләре үзеннән-үзе мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган буларак карала алмый, конкрет эшен хәл итүдә күрсәтелгән аспектта кулланылмаган һәм кулланылырга тиеш булмаган, шуңа бәйле рәвештә аның шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында билгеләнгән критерийларга җавап бирми һәм шул нигездә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга алына алмый.

Бу шартларда Татарстан Республикасы Законының 8 статья-

сындагы нигезләмәләрнең алга таба конституциячеллеген бәяләү аны абстракт нормоконтроль тәртибендә тикшерүне аңлатыр иде, гражданин шикаяте буенча Татарстан Республикасы Конституция суды «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы таләпләре нигезендә болай эшләргә хокуклы түгел. Мондый хәлнең килеп чыгуы «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясы нигезендә мөрәҗәгатьне карауга алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Шикаять белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең конституциячеллегенә формаль рәвештә дәгъва белдереп, гражданин Д.Ә. Минапов Татарстан Республикасы Конституция суды алдына гамәлдәге норматив хокукый җайга салуны камилләштерү кирәклеге турындагы мәсьәләне куя. Шул ук вакытта куелган мәсьәләне хәл итү, Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6, 7 һәм 8 статьялары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Д.Ә. Минапов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Д.Ә. Минаповка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 17-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Л.П. Павлухина на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1.1 и разделом 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан»**

10 июня
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина Л.П. Павлухина,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин Л.П. Павлухин с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1.1 и разделом 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» (далее также — Положение).

Оспариваемый пункт 1.1 указанного Положения устанавливает, что данное Положение регламентирует порядок и условия предоставления субсидий отдельным категориям граждан, имеющим право на скидку в оплате жилья и коммунальных услуг в соответствии с законодательствами Российской Федерации и Республики Татарстан (далее – субсидии-льготы), а раздел 4 определяет механизм предоставления субсидии-льготы.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданин Л.П. Павлухин является инвалидом и ветераном труда, проживает совместно со своей супругой, которая является также ветераном труда, в частном доме в пгт. Нижние Вязовые Зеленодольского района Республики Татарстан. Ему, как инвалиду, на основании Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» в 2016 году назначена субсидия-льгота на оплату жилья и коммунальных услуг. За период с ноября 2017 года у заявителя образовалась задолженность по оплате коммунальных услуг.

Как отмечает в своей жалобе гражданин Л.П. Павлухин, указанная задолженность возникла по той причине, что начисляемая ему субсидия поступает на его расчетный счет после срока оплаты им жилого помещения и коммунальных услуг. Решением мирового

судьи судебного участка № 8 по Зеленодольскому судебному району Республики Татарстан, оставленным без изменения апелляционным определением Зеленодольского городского суда Республики Татарстан исковые требования АО «Татэнергосбыт» в лице филиала «Буинское отделение» к нему о взыскании задолженности за потребленную электроэнергию были удовлетворены. Определением судьи Верховного суда Республики Татарстан заявителю было отказано в передаче кассационной жалобы для рассмотрения в судебном заседании кассационной инстанции Верховного суда Республики Татарстан.

По мнению гражданина Л.П. Павлухина, обжалуемый пункта 1.1 Положения, исходя из своего буквального содержания, не регламентирует порядок и условия предоставления субсидий-льгот инвалидам, поскольку как он считает, инвалиды относятся к категории граждан, имеющих право на скидку в оплате жилья и коммунальных услуг в соответствии с законодательством Российской Федерации. Вместе с этим, он отмечает, что слово «отдельным» в оспариваемой норме не указывает на инвалидов, подпадающих под действие названного Положения. Ему неясно, в соответствии с каким нормативным актом в Республике Татарстан предоставляются субсидии-льготы на оплату жилья и коммунальных услуг на основании Федерального закона «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации».

Кроме этого, раздел 4 обжалуемого Положения, как утверждает заявитель, устанавливая механизм предоставления субсидии-льготы, не определяет, когда она предоставляется: до срока внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги или после и возможно ли за счет субсидий производить оплату жилого помещения и коммунальных услуг.

В своей жалобе гражданин Л.П. Павлухин указывает, что в силу неопределенного содержания раздела 4 Положения порядок оплаты жилого помещения и коммунальных услуг субсидиями оставлен на произвольное решение правоприменительного органа, который фактически ничем не ограничен в своем усмотрении и может предоставить субсидию-льготу как до срока внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги, так и после наступления этого срока. Тем самым реальный механизм предоставления субсидии-льготы в разделе 4 Положения отсутствует.

На основании изложенного заявитель просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 1.1 и раздел 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», не соответствующими статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 48 (часть вторая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с частью 1 статьи 160 Жилищного кодекса Российской Федерации отдельным категориям граждан в порядке

и на условиях, которые установлены федеральными законами, законами субъектов Российской Федерации и нормативными правовыми актами органов местного самоуправления, могут предоставляться компенсации расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг за счет средств соответствующих бюджетов.

На основании Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» (в редакции Федерального закона от 29 декабря 2004 года № 199-ФЗ) полномочия по предоставлению мер социальной поддержки инвалидов по оплате жилого помещения и коммунальных услуг с 1 января 2005 года переданы органам государственной власти субъектов Российской Федерации (статья 28.2, часть 1). Данным Федеральным законом также предусмотрено, что форма предоставления указанных мер социальной поддержки определяется нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации (статья 28.2, часть 6).

В рамках реализации Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ «О внесении изменений в законодательные акты Российской Федерации и признании утратившими силу некоторых законодательных актов Российской Федерации в связи с принятием Федеральных законов «О внесении изменений и дополнений в Федеральный закон «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» и «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» и в силу указанных выше норм федерального законодательства, Кабинет Министров Республики Татарстан постановлением от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» утвердил Положение о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан.

Оспариваемый заявителем пункт 1.1 Положения исходя из его содержания направлен на определение предмета регулирования Положения, а именно регламентацию порядка и условий предоставления субсидий отдельным категориям граждан, имеющим право на скидку в оплате жилья и коммунальных услуг. Что касается категории граждан, которым предоставляются субсидии на оплату жилья и коммунальных услуг, то необходимо отметить, что во исполнение Федерального закона от 27 июля 2010 года № 210-ФЗ «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг» и в целях реализации обжалуемого постановления Кабинета Министров Республики Татарстан приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 19 ноября 2014 года № 634 утвержден Административный регламент предоставления государственной услуги по назначению субсидии-льготы на оплату жилого помещения и коммунальных услуг, которым к категориям граждан, имеющим право на получение субсидии-льготы отнесены и инвалиды (подпункт 11 пункта 1.2).

Таким образом, пункт 1.1 Положения не содержит неопреде-

ленности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан, поскольку пункт 1.1 подлежит применению в системном единстве с иными нормами федерального и республиканского законодательства, относящих инвалидов к категории граждан, обладающих правом на предоставление мер социальной поддержки.

Что касается вопроса об отсутствии в разделе 4 Положения конкретных сроков предоставления субсидии-льготы по оплате жилья и коммунальных услуг следует отметить, что сам по себе рассматриваемый раздел направлен на определение способа получения гражданами субсидии-льготы и возможности выбора такими гражданами наиболее удобного способа ее получения. Оспариваемый заявителем раздел 4 Положения, как и само Положение в целом, находится в системной взаимосвязи с постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20, регулирующим Порядок информационного обмена между организациями — участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат. В силу подпункта 20 пункта 6 вышеуказанного Порядка перечисление субсидий на оплату жилого помещения, коммунальных услуг производится в срок до 9 числа месяца ее выплаты. Тем самым такое правовое регулирование не препятствует гражданам производить оплату за жилое помещение и коммунальные услуги за счет указанной субсидии-льготы. На этом основании довод заявителя о том, что в разделе 4 Положения отсутствует срок предоставления субсидии-льготы по оплате жилья и коммунальных услуг, является необоснованным.

Таким образом, обжалуемые нормы Положения сами по себе не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права граждан, в том числе гражданина Л.П. Павлухина, и, следовательно, не содержат неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявителя не является допустимой.

Исследование обстоятельств образовавшейся задолженности по оплате жилого помещения и коммунальных услуг у заявителя, а также вопроса о конкретных сроках поступления субсидии на его счет не относятся к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, поскольку в силу части девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Консти-

туционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Л.П. Павлухина на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1.1 и разделом 4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных заявителем вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину Л.П. Павлухину и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 19-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәнең 1.1 пункты һәм 4 бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Л.П. Павлухин шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
10 июнь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Л.П. Павлухин шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Л.П. Павлухин «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 1.1 пункты һәм 4 бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Күрсәтелгән Нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 1.1 пунктында билгеләнгәнчә, әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә ташламага хокукы булган гражданнарның аерым категорияләренә субсидияләр (алга таба — ташлама-субсидияләр) бирү тәртибен һәм шартларын регламентлаштыра, ә 4 бүлек ташлама-субсидияләр бирү механизмын билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Л.П. Павлухин инвалид һәм хезмәт ветераны, шулай ук хезмәт ветераны булган хатыны белән бергә Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы Түбән Вязовые шәһәр тибындагы поселогында шәхси йортында яши. Аңа, инвалид буларак, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге

181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2016 елда торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия билгеләнгән. 2017 елның ноябреннән бирле мөрәҗәгать итүченең коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә бурычлары барлыкка килгән.

Гражданин Л.П. Павлухин үзенең шикаятендә билгеләп үткәнчә, әлеге бурыч үзенә исәпләнгән субсидиянең торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү срогыннан соң гына аның исәп-хисап счетына кертелүе сәбәпле килеп чыккан. Татарстан Республикасы Яшел Үзән суд районы буенча 8 нче суд участогы җәмәгать судьясы карары белән, Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәр судының апелляция билгеләмәсе үзгәрешсез калдырылып, «Буа бүлекчәсе» филиалы аша «Татэнергосбыт» АҖнең аңа кулланылган электр энергиясе өчен бурычларын түләтү турындагы дәгъва таләпләре канәгатьләндерелгән. Татарстан Республикасы Югары суды судьясы билгеләмәсе белән мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы Югары суды кассация инстанциясенең суд утырышында карау өчен кассация шикаятен тапшырудан баш тартылган.

Гражданин Л.П. Павлухин фикеренчә, шикаять белдерелә торган Нигезләмәнең 1.1 пункты, үзенең турыдан-туры эчтәлегеннән чыгып, инвалидларга ташлама-субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын регламентлаштырмый, чөнки, ул санаганча, инвалидлар Россия Федерациясе законнары нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама алу хокукы булган гражданнар категориясенә керә. Шуның белән бергә, ул, дәгъва белдерелә торган нормада «аерым» сүзе әлеге Нигезләмәгә туры килгән инвалидларны күрсәтми, дип билгеләп үтә. Аңа «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында нинди норматив акт нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирелүе аңлашылмый.

Моннан тыш, шикаять белдерелә торган Нигезләмәнең 4 бүлеге, мөрәҗәгать итүче раславынча, ташлама-субсидияләр бирү механизмын билгеләп, аның кайчан бирелгәнен билгеләми: торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү срогы чыкканчыга кадәрме яки аннан соңмы һәм субсидияләр хисабына торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләргә мөмкинме.

Үзенең шикаятендә гражданин Л.П. Павлухин Нигезләмәнең 4 бүлегендәге билгесезлек нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен субсидияләр белән түләү тәртибе асылда берни белән дә чикләнмәгән хокук куллану органының иркле карарына калдырылган, дип күрсәтә һәм ул торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү вакытына кадәр дә, шул вакыт җиткәннән соң да ташлама-субсидия бирә ала. Шуның белән Нигезләмәнең 4 бүлегендә ташлама-субсидияләр бирүнең реаль механизмы юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2006 елның 24 мартындагы

126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Нигезләмәнең 1.1 пунктын һәм 4 бүлеген Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 48 (икенче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 160 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә киткән чыгымнарны компенсацияләү өчен тиешле бюджет акчалары исәбеннән бирелергә мөмкин.

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (2004 елның 29 декабрендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 2005 елның 1 гыйнварыннан торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча вәкаләтләр Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган (28.2 статья, 1 өлеш). Әлеге Федераль закон белән шулай ук социаль ярдәмнең күрсәтелгән чараларын бирү формасы Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары белән билгеләнә дип каралган (28.2 статья, 6 өлеш).

«Федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында һәм югарыда күрсәтелгән федераль закон нормалары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслады.

Мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган Нигезләмәнең 1.1 пункты аның эчтәлегеннән чыгып, Нигезләмәне җайга салу предметын билгеләүгә, атап әйткәндә, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама хокукы булган гражданнарның аерым категорияләренә субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын регламентлауга юнәлдерелгән. Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирелә торган гражданнар катего-

риясенә килгәндә, шуны да билгеләп үтәргә кирәк: «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының шикаять белдерелә торган карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы белән торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты расланган, ташлама-субсидияләр алу хокукына ия гражданнар категориясенә инвалидлар да кертелгән (1.2 пунктның 11 пунктчасы).

Шулай итеп, Нигезләмәнең 1.1 пунктында аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк, чөнки 1.1 пункты инвалидларны социаль ярдәм чаралары бирү хокукына ия булган гражданнар категориясенә караган федераль һәм республика законнарының башка нормалары белән системалы бердәмлектә кулланылырга тиеш.

Нигезләмәнең 4 бүлегендә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча ташлама-субсидияләр бирүнең конкрет сроклары булмау мәсьәләсенә килгәндә, каралучы бүлек үзе гражданнар тарафыннан ташлама-субсидияләр алу ысулын һәм мондый гражданнар тарафыннан аны алуның иң уңайлы ысулын сайлау мөмкинлегенә юнәлдерелгән булуын билгеләп үтәргә кирәк. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Нигезләмәнең 4 бүлеге, тулаем Нигезләмә кебек үк, торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибен җайга сала торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән системалы элемтәдә тора. Югарыда күрсәтелгән Тәртипнең 6 пунктындагы 20 пунктчасы нигезендә торак, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләр күчерү айның 9 числосына кадәр башкарыла. Шуның белән мондый хокукый җайга салу гражданнарга күрсәтелгән ташлама-субсидияләр хисабына торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә комачауламый. Шул нигездә, мөрәҗәгать итүченең Нигезләмәнең 4 бүлегендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча ташлама-субсидияләр бирү срогы булмавы турындагы дәлиле нигезсез.

Шулай итеп, шикаять белдерелә торган Нигезләмә нормалары үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданин Л.П. Павлухинның конституциячел хокукларын бозучы буларак карала алмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте мөмкин түгел.

Мөрәҗәгать итүчедә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән бурычларны тикшерү, шулай ук аның исәбенә субсидия күчерүнең конкрет сроклары турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары яисә башка судлар компетенциясенә кергән барлык очракларда да, конституциячел суд эшләрен гамәлгә ашырганда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәнең 1.1 пункты һәм 4 бүлеге белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Л.П. Павлухин шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять бирелергә мөмкин түгел, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Әлеге шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Л.П. Павлухинга һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 19-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

10 июня
2019 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Н.М. Маркиной на нарушение ее конституционных прав и свобод отдельными положениями Правил благоустройства города Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 18 октября 2006 года № 4-12**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Ф.Р. Волковой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Н.М. Маркиной,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Н.М. Маркина с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 9, 206, подпунктами 207.1 и 207.3 пункта 207 Правил благоустройства города Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 18 октября 2006 года № 4-12 (далее также — Правила).

В соответствии с пунктом 9 Правил физические и юридические лица независимо от их организационно-правовых форм осуществляют содержание и уборку территории земельного участка, принадлежащего им на праве собственности, ином вещном либо обязательственном праве, и прилегающей территории, а также зданий, сооружений в объеме, предусмотренном действующим законодательством и Правилами, самостоятельно или посредством привлечения специализированных организаций за счет собственных средств. В случае если здание, сооружение принадлежат на праве собственности или ином вещном либо обязательственном праве нескольким лицам, территория, подлежащая уборке, определяется пропорционально доле в праве собственности или ином праве на объект недвижимости. В случае если на территории земельного участка находятся несколько зданий, сооружений, принадлежащих разным лицам, границы содержания и уборки территории могут определяться соглашением сторон. При отсутствии соглашения территория, подлежащая уборке, определяется в равных долях между всеми собственниками или иными владельцами (пользователями) зданий, сооружений. В случае если земельный участок, находящийся во владении физического или юридического лица, не оформлен в установленном порядке, уборке подлежит территория по фактически сложившейся границе земельного участка, находящегося во владении, а также прилегающая территория. В случае если здание, сооружение принадлежат на праве собственности или ином вещном либо обязательственном праве нескольким лицам, содержание фасада может определяться соглашением сторон. При отсутствии соглашения содержание фасада осуществляется

пропорционально доле в праве собственности или в ином праве на объект недвижимости.

Пункт 206 Правил предусматривает, что в целях обеспечения надлежащего санитарного состояния территорий города, реализации мероприятий по охране и защите окружающей среды от загрязнения территории города закрепляются для их уборки и санитарного содержания за хозяйствующими субъектами и физическими лицами в качестве прилегающих территорий.

Согласно пункту 207 Правил обязанности по производству работ по уборке, очистке и санитарному содержанию территорий (земельных участков) возлагаются на физических и юридических лиц независимо от их организационно-правовой формы в следующем порядке, если иное не предусмотрено законом или договором:

управляющие организации — придомовая территория многоквартирных домов, а также земельный участок перед территорией многоквартирного дома со стороны главного фасада в радиусе 5 м либо до проезжей части улицы (в случае расположения объекта вдоль дороги) (подпункт 207.1);

лица, эксплуатирующие встроенные нежилые помещения в многоквартирных жилых домах, осуществляют уборку прилегающей территории в длину — на протяжении всей длины помещений, в ширину — на расстоянии 10 м либо до бордюра проезжей части (в случае расположения объекта вдоль дороги) в случае отсутствия договора с управляющей организацией (подпункт 207.3).

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданка Н.М. Маркина является собственником нежилого помещения, расположенного в цокольном этаже многоквартирного дома в городе Казани, управление которым осуществляет товарищество собственников жилья (далее также — ТСЖ). Не согласившись с начислением ей платы за дополнительные услуги по уборке прилегающей к дому территории, она обратилась в суд с иском к ТСЖ. В свою очередь ТСЖ предъявило встречный иск о взыскании задолженности по жилищно-коммунальным услугам, по которым решениями общих собраний членов этого ТСЖ была установлена пропорциональная плата по производству санитарной уборки территории, прилегающей к дому. Решением Вахитовского районного суда города Казани в удовлетворении исковых требований заявительницы к ТСЖ отказано, встречное исковое заявление удовлетворено частично, и с нее взыскана задолженность за жилищно-коммунальные услуги. Апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан указанное судебное решение изменено, подлежащая взысканию с заявительницы сумма увеличена.

Как отмечает гражданка Н.М. Маркина в соответствии с пунктом 8 Правил, организацию содержания и уборки территорий общего пользования, в том числе земельных участков, занятых площадями, улицами, проездами, автомобильными дорогами местного значения, набережными, скверами, бульварами, пляжами, другими объектами, осуществляют уполномоченные органы в пределах своих полномочий. В связи с этим она считает, что

пункт 9 и подпункт 207.3 пункта 207 Правил, обязывающие собственников нежилых помещений производить уборку за пределами земельных участков, правообладателями которых они являются, и устанавливающие размеры земельных участков для уборки прилегающей территории в длину — на протяжении всей длины помещений, в ширину — на расстоянии 10 м либо до бордюра проезжей части (фактически являющейся территорией общего пользования и муниципальной собственностью), противоречат не только Конституции Республики Татарстан, но и пункту 8 Правил. Органы местного самоуправления города Казани, по мнению заявительницы, установив в Правилах размеры прилегающей территории, подлежащей уборке собственниками нежилых помещений, превысили свои полномочия и ограничили ее права собственника.

На основании изложенного гражданка Н.М. Маркина просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункты 9, 206, подпункты 207.1 и 207.3 пункта 207 Правил благоустройства города Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 18 октября 2006 года № 4-12, не соответствующими статьям 19 и 118 Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» (далее — Федеральный закон № 131-ФЗ) к вопросам местного значения городского округа относится утверждение правил благоустройства территории городского округа, осуществление контроля за их соблюдением, организация благоустройства территории городского округа в соответствии с указанными правилами (пункт 25 части 1 статьи 16). Идентичные по содержанию положения закреплены в пункте 25 части 1 статьи 17 Закона Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан».

Утверждение правил благоустройства территории муниципального образования пунктом 11 части 10 статьи 35 Федерального закона № 131-ФЗ отнесено к исключительной компетенции представительного органа муниципального образования. Согласно пункту 13 части 2 статьи 45.1 данного Федерального закона правила благоустройства территории муниципального образования могут регулировать, в частности, вопросы участия, в том числе финансового, собственников и (или) иных законных владельцев зданий, строений, сооружений, земельных участков (за исключением собственников и (или) иных законных владельцев помещений в многоквартирных домах, земельные участки под которыми не образованы или образованы по границам таких домов) в содержании прилегающих территорий, а также вопросы определения границ прилегающих территорий в соответствии с порядком, установленным законом субъекта Российской Федерации (пункт 14 части 2 статьи 45.1).

Как следует из пункта 36 статьи 1 Градостроительного кодекса Российской Федерации благоустройство территории — это деятельность по реализации комплекса мероприятий, установленного правилами благоустройства территории муниципального образования, направленная на обеспечение и повышение комфортности

условий проживания граждан, по поддержанию и улучшению санитарного и эстетического состояния территории муниципального образования, по содержанию территорий населенных пунктов и расположенных на таких территориях объектов, в том числе территорий общего пользования, земельных участков, зданий, строений, сооружений, прилегающих территорий. В этой же статье дано определение понятия «прилегающая территория», под которой понимается территория общего пользования, прилегающая к зданию, строению, сооружению, земельному участку в случае, если такой земельный участок образован, и границы которой определены правилами благоустройства территории муниципального образования в соответствии с порядком, установленным законом субъекта Российской Федерации (пункт 37).

В силу взаимосвязанных положений частей 1 и 9 статьи 55.25 Градостроительного кодекса Российской Федерации лицом, ответственным за эксплуатацию здания, сооружения (за исключением собственников и (или) иных законных владельцев помещений в многоквартирных домах, земельные участки под которыми не образованы или образованы по границам таких домов), обязанным принимать участие, в том числе финансовое, в содержании прилегающих территорий в случаях и порядке, которые определяются правилами благоустройства территории муниципального образования, является, если иное не предусмотрено федеральным законом, собственник здания, сооружения или лицо, которое владеет зданием, сооружением на ином законном основании (на праве аренды, хозяйственного ведения, оперативного управления и другое) в случае, если соответствующим договором, решением органа государственной власти или органа местного самоуправления установлена ответственность такого лица за эксплуатацию здания, сооружения, либо привлекаемое собственником или таким лицом в целях обеспечения безопасной эксплуатации здания, сооружения на основании договора физическое или юридическое лицо. Тем самым федеральным законодательством закреплено участие собственника зданий, сооружений, земельных участков в содержании территорий, прилегающих к соответствующим объектам собственности.

Как отметил Конституционный Суд Российской Федерации, положения статьи 55.25 Градостроительного кодекса Российской Федерации, предусматривающие возможность привлечения собственником (иным владельцем) на основании договора физического или юридического лица в целях обеспечения безопасной эксплуатации здания (осуществления технического обслуживания, эксплуатационного контроля, текущего ремонта), сооружения и признающие такое лицо в качестве лица, ответственного за эксплуатацию здания, сооружения, не могут рассматриваться как исключающие в указанном случае возможность проведения мероприятий государственного контроля (надзора) при эксплуатации зданий, сооружений в отношении самого собственника здания, сооружения, имея в виду, что данные положения, рассматриваемые во взаимосвязи с положениями статей 209 и 210 Гражданского кодекса Российской Федерации, не означают снятия с собственни-

ка здания бремени содержания принадлежащего ему имущества (Определение от 28 февраля 2017 года № 461-О).

Из этого следует, что обязанность собственников в содержании прилегающих территорий возникает у них непосредственного в силу Федерального закона № 131-ФЗ и Градостроительного кодекса Российской Федерации, а также согласуется со статьей 210 Гражданского кодекса Российской Федерации, устанавливающей, что собственник несет бремя содержания, принадлежащего ему имущества, если иное не предусмотрено федеральным законом.

В соответствии с указанными законоположениями в оспариваемых заявительницей нормах Правил установлены общие требования к содержанию и уборке территории земельного участка, принадлежащего физическим и юридическим лицам на праве собственности, ином вещном или обязательственном праве, и прилегающей территории, а также зданий, сооружений в объеме, предусмотренном действующим законодательством (пункт 9), и предусмотрен порядок участия, как собственников зданий (помещений в них) и сооружений, так и иных лиц в реализации мероприятий по благоустройству прилегающих территорий (пункты 206, 207), с указанием для каждого из них границ конкретных участков по осуществлению работ по уборке, очистке и санитарному содержанию территорий (земельных участков) (подпункты 207.1-207.16 пункта 207).

Таким образом, оспариваемые положения Правил, представляющие собой в том числе комплекс мер по содержанию территории городского округа и требования к ее благоустройству, по своей юридической природе имеют исключительно организационную направленность и приняты Казанской городской Думой в пределах предоставленных ей полномочий. При этом обжалуемые нормы Правил не устанавливают иное правовое регулирование, отличающееся от приведенных требований федерального законодательства, и сами по себе не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права граждан, в том числе и заявительницы. Следовательно, указанные нормы не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки Н.М. Маркиной не является допустимой.

Из содержания жалобы следует, что заявительница, формально оспаривая конституционность рассматриваемых положений Правил благоустройства города Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 18 октября 2006 года № 4-12, фактически выражает несогласие с решениями правоприменительных органов, оценка законности и обоснованности которых не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи

46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Н.М. Маркиной на нарушение ее конституционных прав и свобод отдельными положениями Правил благоустройства города Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 18 октября 2006 года № 4-12, поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Н.М. Маркиной и в Казанскую городскую Думу.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 20-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Казан шәһәре Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Н.М. Маркина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
10 июнь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Н.М. Маркина шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Н.М. Маркина Казан шәһәре Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең (алга таба — Кагыйдәләр) 9, 206 пунктлары, 207 пунктның 207.1 һәм 207.3 пунктчалары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Кагыйдәләрнең 9 пункты нигезендә физик һәм юридик затлар, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, үзләренең милек хокукындагы җир кишәрлеген, башка төрле әйбер яисә йөкләмә хокукындагы җир кишәрлеген һәм аның янәшәсендәге территорияне, шулай ук биналар, корылмаларны гамәлдәге законнарда һәм Кагыйдәләрдә каралган күләмдә мөстәкыйль рәвештә яки үз акчалары хисабына махсуслаштырылган оешмаларны җәлеп итеп, җир кишәрлеге территориясен карап тоталар һәм җыештыралар. Бина, корылма милек хокукында яки башка төрле әйбер яисә йөкләмә хокукында берничә затка караса, җыештырылырга тиешле территория милек хокукына яки күчемсез милек объектына башка хокукка пропорциональ рәвештә билгеләнә. Җир кишәрлеге территориясендә төрле затка караган берничә бина, корылмалар булса, территорияне карап тоту һәм җыештыру чикләре якларның килешүе белән билгеләнергә мөмкин. Килешү булмаса, җыештырылырга тиешле территория барлык милекчеләр яки башка биналарның, корылмаларның хуҗалары (файдаланучылары) арасында тигез өлешләрдә билгеләнә. Физик яки юридик зат карамагында булган җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, җыештырыла торган җир кишәрлегенең фактта барлыкка килгән чиге буенча булган территория, шулай ук янәшә территория җыештырылырга тиеш. Бина, корылма берничә затка милек хокукында яки башка төрле әйбер яисә йөкләмә хокукында булган очракта, фасадны карап тоту яклар килешүе белән

билгеләнергә мөмкин. Килешү булмаганда, фасадны карап тоту милек хокукында яки күчемсез милек объектына башка хокукта өлешкә пропорциональ рәвештә башкарыла.

Кагыйдәләрнең 206 пункты шәһәр территорияләренең тиешле санитар торышын тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне пычратудан саклау һәм яклау чараларын гамәлгә ашыру максатларында хуҗалык итүче субъектларга һәм физик затларга җыештыру һәм санитар карап тоту өчен шәһәр территорияләре янәшә территорияләр буларак беркетелүен күздә тота.

Кагыйдәләрнең 207 пункты нигезендә территорияләрне (җир кишәрлекләрен) җыештыру, чистарту һәм санитар яктан карап тоту эшләрен башкару бурычлары, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, түбәндәге тәртиптә, әгәр законда яки килешүдә башкача каралмаган булса, физик һәм юридик затларга йөкләнә:

идарәче оешмалар — күпфатирлы йортларның йорт яны территориясе, шулай ук төп фасад ягыннан 5 м радиуста күпфатирлы йорт алдындагы җир кишәрлеге яки урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта) (207.1 пунктчасы);

идарәче оешма белән килешү булмаган очракта, күпфатирлы торак йортларда торак булмаган биналарны эксплуатацияләүче затлар янәшә территорияне озынлыкка — бөтен бина озынлыгы буенча, киңлеккә 10 м арада яки юл буендагы бордюрга кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта) җыештыралар (207.3 пунктчасы).

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Н.М. Маркина — Казан шәһәрендәге күпфатирлы йортның аскы катында урнашкан торак милекчеләре ширкәте (алга таба — ТМШ) тарафыннан идарә ителә торган торак булмаган бина милекчесе. Йорт янәшәсендәге территорияне җыештыру буенча өстәмә хезмәтләр өчен түләүне исәпләү белән килешмичә, ул ТМШнә дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткән. Үз чиратында ТМШ торак-коммуналь хезмәтләр буенча бурычларын түләттерү турында каршы дәгъва белдергән, алар буенча әлеге ТМШ әгъзаларының гомуми җыелышлары карарлары белән йорт янәшәсендәге территорияне санитар чистарту буенча пропорциональ түләү билгеләнгән. Казан шәһәре Вахитов район суды карары белән мөрәҗәгать итүченең ТМШнә карата дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган, каршы дәгъва гаризасы өлешчә канәгатьләндерелгән һәм аннан торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурыч түләттерелгән. Татарстан Республикасы Югары суды граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән күрсәтелгән суд карары үзгәртелгән, мөрәҗәгать итүчедән түләттерелергә тиешле сумма арттырылган.

Гражданка Н.М. Маркина билгеләп үткәнчә, Кагыйдәләрнең 8 пункты нигезендә, гомуми файдаланудагы территорияләрне, шул исәптән мәйданнар, урамнар, юллар, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, яр буйлары, скверлар, бульварлар, пляжлар, башка объектлар биләгән җир кишәрлекләрен карап тотуны һәм җыештыруны оештыруны вәкаләтле органнар үз вәка-

ләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра. Шуңа бәйле рәвештә, ул, торак булмаган биналарның милекчеләрен үзләре ия булган җир кишәрлекләреннән тыш, озынлыкка — бөтен бина озынлыгы буенча, киңлеккә — 10 м арада яки юл буендагы бордюрга кадәр (фактта гомуми файдалану территориясе һәм муниципаль милек булып тора) җыештырырга мәҗбүр итә торган һәм янәшә территорияне чистарту өчен җир кишәрлекләре күләмнәрен билгели торган Кагыйдәләрнең 9 пункты һәм 207 пунктның 207.3 пунктчасы Татарстан Республикасы Конституциясенә генә түгел, ә Кагыйдәләрнең 8 пунктына да каршы килә дип саный. Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Кагыйдәләрдә торак булмаган биналарның милекчеләре тарафыннан җыештырылырга тиешле янәшә территориянең күләмен билгеләп, үз вәкаләтләрен арттырганнар һәм аның милекче буларак хокукларын чикләгәннәр.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Н.М. Маркина Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү Кагыйдәләренең 9, 206, 207 пунктның 207.1 һәм 207.3 пунктчаларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 19 һәм 118 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба — 131-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә шәһәр округы территориясен төзекләндерүне оештыру шәһәр округының җирле әһәмияткә ия мәсьәләләренә керә (16 статьяның 1 өлешендәге 25 пункты). Эчтәлеге буенча охшаш нигезләмә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы 1 өлешенең 25 пунктында беркетелгән.

Муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статья сындагы 10 өлешенең 11 пункты белән муниципаль берәмлек вәкиллекле органының аерым компетенциясенә кертелгән. Әлеге Федераль законның 45.1 статьясындагы 2 өлешенең 13 пункты нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре, аерым алганда биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, җир кишәрлекләренең милекчеләре һәм (яки) башка законлы хуҗаларының (астында җир кишәрлекләре тормаган яки мондый йортлар чикләре буенча җир кишәрлеге ясалган күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләреннән һәм (яисә) башка законлы хуҗаларыннан тыш) янәшә территорияләрне карап тотуда катнашу мәсьәләләрен, шул исәптән финанс мәсьәләләрен, шулай ук Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә (45.1 статьяның 2 өлешендәге 14 пункты) янәшә территорияләр чикләрен билгеләү мәсьәләләрен җайга сала алалар.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясындагы 36 пунктыннан күренгәнчә, территорияне төзекләндерү — муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыруга, гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм уңайлылыгын күтәрүгә юнәлдерелгән, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итү һәм яхшырту, торак пунктлар территорияләрен һәм шундый территорияләрдә урнашкан объектларны карап тоту буенча, шул исәптән гомуми кулланылыштагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, янәшә территорияләрне карап тоту буенча эшчәнлек ул. Шул ук статьяда, «янәшә территория» төшенчәсенә билгеләмә, әгәр мондый җир кишәрлеге барлыкка килгән һәм чикләре Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракта, бина, төзелмә, корылма, җир кишәрлеге янәшәсендәге гомуми файдаланудагы территория икәнлеге аңлашыла, дип бирелгән (37 пункт).

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.25 статьясындагы 1 һәм 9 өлешләренең үзара бәйле нигезләмәләре буенча, бинаны, корылманы файдалану өчен җаваплы зат (астында җир кишәрлекләре тормаган яки мондый йортлар чикләре буенча җир кишәрлеге ясалган күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләреннән һәм (яисә) башка законлы хуҗаларыннан тыш), муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнә торган очракларда һәм тәртиптә янәшә территорияләрне, шул исәптән финанс ягыннан да, карап тотуда катнашырга тиешле, әгәр федераль законда башкача каралмаган булса, бина, корылма милекчесе яисә бүтән законлы нигездә (аренда, хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукында һәм башкалар) бина, корылма иясе булган зат тиешле килешү белән, дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы карары белән мондый затның бинаны, корылманы эксплуатацияләгән өчен җаваплылыгы билгеләнгән очракта, яки милекче һәм мондый зат тарафыннан бинаны, корылманы килешү нигезендә куркынычсыз эксплуатацияләүне тәэмин итү максатларында җәлеп ителгән физик яки юридик зат булып тора. Шул ук федераль законнарда биналар, корылмалар, җир кишәрлекләре милекчеләренең тиешле милек объектлары янәшәсендәге территорияләрне карап тотуда катнашуы беркетелгән.

Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, корылманы, бинаны куркынычсыз эксплуатацияләүне тәэмин итү (техник хезмәт күрсәтүне, эксплуатацион контрольне, агымдагы ремонтны гамәлгә ашыру) максатларында милекче (башка хуҗа) белән физик яки юридик зат шартнамәсе нигезендә җәлеп итү мөмкинлеген күздә тота торган һәм мондый затны бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы зат буларак таный торган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.25 статьясы нигезләмәләре бина, корылма милекчесенең үзенә карата биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә күрсәтелгән

очракта дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын уздырмый калу мөмкинлеген бирүче буларак карала алмыйлар, шуны күздә тотып, Россия Федерациясе Граждан кодексының 209 һәм 210 статьялары нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә карала торган әлеге нигезләмәләр бина милекчесен үз мөлкәтен карап тоту җаваплылыгыннан азат итүне аңлатмый (2017 елның 28 февралендәге 461-О номерлы билгеләмә).

Моннан күренгәнчә, милекчеләрнең янәшәдәге территорияләрне карап тоту бурычы аларда турыдан-туры 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә барлыкка килә, шулай ук милекченең үзенә караган мөлкәтне карап тоту бурычын билгели торган, әгәр федераль законда башкача каралмаган булса, Россия Федерациясе Граждан кодексының 210 статьясына туры килә.

Күрсәтелгән законнар нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләрдә физик һәм юридик затларга милек хокукындагы, башка төрле әйбер яисә йөкләмә хокукындагы җир кишәрлеге территориясен һәм аның янәшәсендәге территорияне, шулай ук биналарны, корылмаларны гамәлдәге законнарда каралган күләмдә карап тотуга һәм җыештыруга карата гомуми таләпләр билгеләнгән (9 пункт) һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруда биналар (андагы бүлмәләр) һәм корылмалар милекчеләренең дә, шулай ук башка затларның да катнашу тәртибе каралган (206, 207 пунктлар), аларның һәркайсы өчен территорияләрне (җир кишәрлекләрен) җыештыру, чистарту һәм санитар карап тоту эшләрен башкару буенча конкрет участокларның чикләре күрсәтелгән (207 пунктның 207.1-207.16 пунктчалары).

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләрнең шул исәптән шәһәр округы территориясен карап тоту буенча чаралар комплексы һәм аны төзекләндерүгә карата таләпләр булган нигезләмәләре үзенең юридик табигате буенча бары тик оештыру юнәлешенә ия һәм Казан шәһәре Думасы тарафыннан үзенә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгән. Шул ук вакытта Кагыйдәләрнең шикаять белдерелә торган нормалары федераль законнарның күрсәтелгән таләпләреннән аерылып торучы башка хокукый җайга салуны билгеләмиләр һәм үзлегеннән гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын бозучы буларак карала алмыйлар. Димәк, күрсәтелгән нормаларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә гражданка Н.М. Маркина шикаяте карала алмый.

Шикаять эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче, Казан шәһәре Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең карала торган нигезләмәләренең конституциячеллеген формаль

рәвештә дәгъвалап, Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгәнчә, законлылыгын һәм нигезлелеген бәяләү Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми торган хокук куллану органнары карарлары белән килешмәүне белдерә.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясының икенче өлешендәге 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Н.М. Маркина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының билгеләнгән таләпләре нигезендә мөмкин түгел, ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Н.М. Маркинага һәм Казан шәһәре Думасына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 20-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# РАЗДЕЛ II.

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# РЕШЕНИЕ
# КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О поощрении благодарственными письмами Конституционного суда Республики Татарстан**

г. Казань 7 марта 2019 года

В соответствии с Положением о Благодарственном письме Конституционного суда Республики Татарстан, утвержденным решением Конституционного суда Республики Татарстан от 1 марта 2012 года № 1-Р, Конституционный суд Республики Татарстан

**р е ш и л :**

За многолетнюю плодотворную работу, обеспечение эффективной работы отдела подготовки судебных заседаний и редакционно-издательской работы Конституционного суда Республики Татарстан поощрить Благодарственным письмом Конституционного суда Республики Татарстан:

— Камалову Гузель Галиевну, ведущего специалиста отдела подготовки судебных заседаний и редакционно-издательской работы аппарата Конституционного суда Республики Татарстан.

№ 1-Р

Конституционный суд
Республики Татарстан

## ДЛЯ ЗАМЕТОК

ДЛЯ ЗАМЕТОК

## ДЛЯ ЗАМЕТОК